ГОСУДАРСТВЕННАЯ
ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Б.Красная, 15/9, г.Казань, 420111

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ДӘҮЛӘТ
ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ
Б.Краснаяур. 15/9, Казан шәһәре, 420111

тел/факс. 236-91-44. E-mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru

№ 201

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

«17» декабрь, 2014 ел.

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензия контролендә тоту буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентын раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шщхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә, «Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү турында» 2014 елның 28 октябрендәге 1110 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт функцияләрен үтәүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2012 елның 31 декабрендәге 1192 номерлы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 12.02.2013 № 97, 10.07.2014 № 484 карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензия контролендә тоту буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентын расларга (кушымталары белән бергә).

2. Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензия контролендә тоту буенча дәүләт функциясен үтәгәндә Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе (алга таба - ТР ДТИ) вазыйфаи

затларына расланган административ регламентка таянып эш итәргә.

3. Административ практика бүлеге җитәкчесенә (Мөхәммәтшин Ф.Р.) ТР ДТИ җитәкчесе урынбасарларын, зональ торак инспекцияләре җитәкчеләрен, ТР ДТИ контрольлек функцияләрен гамәлгә ашыручы бүлекләре җитәкчеләрен һәм вазыйфаи затларын кул куйдыртып, әлеге Боерык белән таныштырырга.

4. Юридик бүлек башлыгына (Гафиятуллин А.М.) әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына теркәү өчен җибәрергә.

5. Әлеге Боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Җитәкче С.А.Крайнов

Татарстан Республикасы Дәүләт
торак инспекциясенең 2014 елның
17 декабрендәге 201 номерлы
боерыгы белән расланды

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕНЕҢ КҮПФАТИРЛЫ ЙОРТЛАР БЕЛӘН ИДАРӘ ИТҮ БУЕНЧА ЭШКУАРЛЫК ЭШЧӘНЛЕГЕН ЛИЦЕНЗИЯ КОНТРОЛЕНДӘ ТОТУ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕН ҮТӘҮНЕҢ АДМИНИСТРАТИВ РЕГЛАМЕНТЫ

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

### Дәүләт функциясе атамасы

1.1. Әлеге Административ регламент (алга таба – Регламент) нигезендә җайга салына торган дәүләт функциясе – күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлегенә лицензия контролен гамәлгә ашыру (алга таба – лицензия контроле).

### Дәүләт хезмәте күрсәтә торган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының исеме

1.2. Лицензиясе булган яисә лицензияләүче органга күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия бирү турында гариза белән мөрәҗәгать иткән (алга таба тиешенчә – лицензиатлар, лицензия алырга теләүчеләр) юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның лицензия таләпләрен үтәвенә лицензия контроле Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе (алга таба – ТР ДТИ) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Дәүләт функциясен турыдан-туры башкаручы булып ТР ДТИ Үзәк инспекторлык бүлеге, ТР ДТИ торак фондына капиталь ремонт ясауны контрольдә тоту бүлеге, ТР ДТИ ТКХ өчен түләүләрнең нигезле булуын тикшерүдә тоту бүлеге (алга таба – Бүлекләр) һәм ТР ДТИ структур бүлекчәләре булып торган территориаль органнары тора: Казан шәһәр торак инспекциясе, Әлмәт зонасы торак инспекциясе, Бөгелмә зонасы торак инспекциясе, Алабуга зонасы торак инспекциясе, Түбән Кама зонасы торак инспекциясе, Түбән Кама зонасы торак инспекциясе, Чаллы зонасы торак инспекциясе, Чистай зонасы торак инспекциясе (алга таба – торак зонасы инспекцияләре).

Дәүләт функциясен гамәлгә ашырганда ТР ДТИ ел саен уздырыла торган планлы тикшерүләрнең проектларын килештерү, планнан тыш тикшерүләрне килештерү өлешендә Татарстан Республикасы прокуратурасы органнары

(алга таба – прокуратура органнары), Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә аттестатланган экспертлар, аккредитацияләү турында Россия Федерациясе законнары нигезендә илкүләм аккредитация системасында аккредитацияләнгән эксперт оешмалары (алга таба – экспертлар, эксперт оешмалары), дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яисә ведомство буйсынуындагы оешмалар белән ведомствоара хезмәттәшлек итү кысаларында Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән исемлеккә (әлеге Регламентның 5 нче кушымтасы) кертелгән документларны һәм (яки) мәгълүматларны сорату өлешендә, лицензиатлар, лицензия алырга теләүчеләр белән үзара хезмәттәшлек итүне гамәлгә ашыра.

Тикшерүләрнең бердәм реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасына (алга таба – тикшерүләрнең бердәм реестры), «Контрольлек (күзәтчелек) эшчәнлеген автоматлаштыру буенча бертип болыт чишелеше» дәүләт мәгълүмат системасына тиешле мәгълүматны кертү билгеләнгән тәртиптә ТР Дәүләт торак инспекциясенең вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Дәүләт функциясен үтәүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге

1.3. Дәүләт вазыйфасы түбәндәгеләргә ярашлы рәвештә гамәлгә ашырыла:

Россия Федерациясе Конституциясе;

Россия Федерациясе Гражданлык кодексы (беренче кисәк) (алга таба – РФ Гражданлык кодексы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1994, № 32, 3301 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы (алга таба – Административ хокук бозулар турында РФ кодексы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2002, №1, 1 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Торак кодексы (алга таба – РФ Торак кодексы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2005, №1, 14 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 59-ФЗ номерлы федераль закон)(Российская газета, 2006, 5 май, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы федераль закон (алга

таба – 294-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2008, №52, 6249 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон), (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 99-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, №19, 2716 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре турында» 2014 елның 29 декабрендәге 473-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 473-ФЗ номерлы федераль закон) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2014, 29 декабрь, басылып чыгу номеры: 0001201412290024, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе гражданины паспорты турында нигезләмә, Россия Федерациясе гражданины паспортының бланк үрнәген һәм тасвирламасын раслау турында» 1997 елның 8 июлендәге 828 номерлы карары (алга таба – 828 номерлы карар) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1997, № 28, 3444 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортта гомуми милекне карап тоту кагыйдәләрен һәм күпфатирлы йортта уртак мөлкәт белән эш итү, аны карап тоту һәм ремонтлау буенча тиешсез сыйфатта һәм (яисә) билгеләнгән озынлыгын артып китүче өзеклекләр белән хезмәтләр күрсәтелгән һәм эшләр башкарылган очракта торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен үзгәрү кагыйдәләрен раслау турында» 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 491 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, № 34, 3680 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контрольлек органнары тарафыннан юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планнарын әзерләү кагыйдәләрен раслау турында» 2010 елның 30 июнендәге 489 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 489 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, №28, 3706 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы турында» 2010 елның 8 сентябрендәге

697 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 38, 4823 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортларда һәм торак йортларда милекчеләргә һәм биналардан файдаланучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтү турында» 2011 елның 6 маендагы 354 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 354 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 22, 3168 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Лицензиянең үрнәк рәвешен раслау турында» 2011 елның 6 октябрендәге 826 номерлы карары (алга таба – 826 номерлы карар) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 42, 5924 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 14 маендагы 410 номерлы карары белән расланган Газ белән тәэмин итү буенча коммуналь хезмәт күрсәтелгәндә йорт эче һәм фатир эче газ җайланмаларыннан файдаланганда һәм аларны карап тотканда куркынычсызлык тәэмин итү өлешендә газдан файдалану кагыйдәләре (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 410 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләр) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2013, № 21, 2648 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 15 маендагы 416 номерлы карары белән расланган Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыру кагыйдәләре (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 416 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләр) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2013, № 21, 2652 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 28 октябрендәге 1110 номерлы карары белән расланган Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү турында нигезләмә (алга таба – Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү турында нигезләмә) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2014, № 44, 6074 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләрнең бердәм реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләре турында» 2015 елның 28 апрелендәге 415 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 415 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2015, №19, 2825 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре резидентларына карата дәүләт контролен (күзәтчелеген), муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле органнар тарафыннан уздырыла торган уртак планлы тикшерүләр турында» 2015

елның 22 октябрендәге 1132 номерлы карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1132 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2015, №44, 6127 статья);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләр оештырганда һәм үткәргәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан документларга һәм (яисә) мәгълүматларга, шул исәптән электрон рәвештә, шушы документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән эш итүче бүтән дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына яисә дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмаларга рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрү һәм аларны түләүсез нигездә алу турында» 2016 елның 18 апрелендәге 323 номерлы карары (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2016 №17, 2418 статья);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) аерым төрләрен оештырганда куркыныч-юнәлешле якын килүне куллану һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 17 августындагы 806 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2016, № 35, 5326 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Зарури таләпләрне һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозуның ярамаганлыгы турында кисәтүләр төзү һәм җибәрү, юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан мондый кисәтүләргә ризасызлыклар бирү һәм аларны карап тикшерү, мондый кисәтүне үтәү турында хәбәр итү кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 10 февралендәге 166 номерлы карары (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2017, №8, 1239 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 24 июнендәге 743 номерлы карары белән расланган Метрополитеннардагы эскалаторлардан тыш, лифтлардан, инвалидларны күтәртү платформаларыннан, пассажир конвейерларыннан (хәрәкәт итүче җәяүле юлларыннан) куркынычсыз файдалануны һәм аларны карап тотуны оештыру кагыйдәләре (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 743 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләр) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2017, № 27, 4044 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Контроль (күзәтчелек) эшчәнлеген автоматлаштыру буенча бертип болыт карары» дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2018 елның 21 апрелендәге 482 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 482 номерлы карары) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2018, 25 апрель, басылып чыгару номеры: 001201804250009, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләр оештырганда һәм

үткәргәндә дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында документлар һәм (яки) мәгълүматлар белән эш итүче башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалардан сорала һәм алына торган документлар һәм (яки) мәгълүматлар исемлеген раслау турында» 2016 елның 19 апрелендәге 724-р номерлы боерыгы (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 724-р номерлы боерыгы) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2016, №18, 2647 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь комплекс буенча дәүләт комитетының «Торак фондын техник эксплуатацияләү кагыйдәләрен һәм нормаларын раслау турында» 2003 елның 27 сентябрендәге 170 номерлы карары (алга таба – Россия Дәүләт төзелеш комитетының 170 номерлы карары) (Российская газета, 2003, 23 октябрь);

Россия Федерациясе Генераль прокуратурасының «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законны тормышка ашыру хакында» 2009 елның 27 мартындагы 93 боерыгы (Законность, № 5, 2009, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында»гы федераль закон нигезләмәләрен тормышка ашыру хакында» 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы (алга таба – Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы) (Российская газета, 2009, 14 май, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының «Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының хөкем ителү һәм (яки) җинаятьчел эзәрлекләү факты булу (булмау) турында яисә җинаятьчел эзәрлекләүне туктату турында белешмәләр бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2011 елның 7 ноябрендәге 1121 номерлы боерыгы (Российская газета, 2012, 11 гыйнвар, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федераль салым хезмәтенең «Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына юридик затлар турында үзгәрешләр кертү турында гариза рәвешен, аны рәсмиләштерүгә карата таләпләрне, шулай ук мондый гариза нигезендә Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына язу теркәү фактын раслый торган документның рәвешен һәм эчтәлеген раслау турында» 2014 елның 9 июнендәге ММВ-7-14/316@ номерлы боерыгы (Российская газета,

2014, 27 июнь, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федераль салым хезмәтенең «Квалификациясе алынган затлар реестрында булган белешмәләрне бирү тәртибен, квалификациясе алынган затлар реестрыннан өземтә һәм соралучы мәгълүматның булмавы турында белешмә формаларын раслау турында» 2014 елның 31 декабрендәге НД-7-14/700@ номерлы боерыгы (Хокукый мәгълүматның рәсми порталы (www.pravo.gov.ru), 2015, 12 май, басылып чыгу номеры – 0001201505120034);

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Россия Федерациясе территориясендә, Ерак Көнчыгыш федераль округы территориясеннән тыш, оештырылган алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентларына карата дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль органнар тарафыннан планнан тыш тикшерүләр уздыруны килештерү тәртибен раслау турында» 2016 елның 19 декабрендәге 817 номерлы боерыгы (алга таба – Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 817 номерлы боерыгы) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2017, 21 март, басылып чыгу номеры: 0001201703210041);

Татарстан Республикасы Конституциясе;

«Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 16-ТРЗ номерлы Закон) (Республика Татарстан, 2014, 2 август, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» 2011 елның 10 октябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 72-ТРЗ номерлы Закон), (Республика Татарстан, 2011, 21 октябрь, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе мәсьәләләре» 2011 елның 26 декабрендәге 1068 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2012, № 10, 0383 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында рискка юнәлдерелгән алым кулланыла торган төбәк дәүләт тикшерүе (күзәтчелеге) төрләре исемлеген раслау турында» 2018 елның 27 сентябрендәге 856 номерлы карары (алга таба – 2018 елның 27 сентябрендәге 856 номерлы ТР МК карары)(Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2018, № 77, 2491 ст.);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 31 октябрендәге 971 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлегенә лицензияле контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның эшчәнлеген билгеле бер куркынычлылык категориясенә кертү критерияләре (алга таба – 971 номерлы ТР МК карары белән расланган критерияләр) (Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы PRAVO.TATARSTAN.RU, 2018, 26 ноябрь, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып).

**Лицензия контроле объекты, лицензия контроленең предметы**

1.4. Лицензия контроленең объекты булып, шул исәптән 473-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентлары булып, күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензиясе булган юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның эшчәнлеге йә, шул исәптән 473-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентлары булып торган, күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия бирү турында гариза белән лицензияләүче органга мөрәҗәгать иткән юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның эшчәнлеге тора.

Алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резиденты бирелгән юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга карата лицензия контроле гамәлгә ашырылганда 473-ФЗ номерлы федераль законның 24 статьясы нигезләмәләре исәпкә алына.

1.5. Лицензия контроленең предметы булып лицензиат, лицензия алырга теләүче тарафыннан тапшырылган гаризаларда һәм документларда аның эшчәнлеге турында булган белешмәләр һәм лицензия таләпләрен үтәү, ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмәләрне башкару буенча күрелә торган чаралар тора.

Регламентта кулланыла торган «лицензиат», «юридик зат», «шәхси эшкуар», «тикшерелә торган зат» төшенчәләре – тигез мәгънәле.

Әгәр юридик затның, шәхси эшкуарның ачыкланган лицензия таләпләре бозылуны бетерү турында күрсәтмәне үтәвенең срогы тәмамлану – планнан тыш тикшерүне уздыру нигезе булып торса, бары тик ТР ДТИ тарафыннан бирелгән күрсәтмәнең үтәлеше генә планнан тыш тикшерүне уздыру предметы булып тора ала.

Тикшерелә торган затка белдерелә торган лицензия таләпләре әлеге Регламентның 3 бүлегендә бәян ителгән.

**Лицензия контролен гамәлгә ашырганда ТР ДТИ дти вазыйфаи затларының хокуклары, бурычлары һәм чикләмәләре**

1.6. ТР ДТИ вазыйфаи затлары Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә түбәндәгеләргә хокуклы:

1) тикшерүләр оештырганда һәм уздырганда түләүсез нигездә, шул исәптән электрон рәвештә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 724-р номерлы боерыгы белән расланган исемлеккә кертелгән документларны һәм (яисә) мәгълүматларны шушы документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән эш итүче бүтән дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалардан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 323 номерлы карарында билгеләнгән чорларда һәм тәртиптә соратырга һәм алырга;

2) дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, юридик затлардан, шәхси эшкуарлардан һәм гражданнардан зарури таләпләрнең үтәлүен тикшерү өчен кирәкле мәгълүматларны һәм документларны нигезләнгән язмача гарызнамәләр нигезендә соратырга һәм алырга;

3) лицензиатларга, лицензия алырга теләүчеләргә лицензия таләпләре бозылуны бетерү турында, лицензия таләпләренең ачыкланган бозуларын, шул исәптән лицензия таләпләрен җитди бозуларны, бетерү турында, күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга карата лицензия таләпләрен үтәүне тәэмин итү буенча чаралар уздыру турында күрсәтмәләр бирергә;

4) лицензия таләпләрен бозуга бәйле административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә, күрсәтелгән административ хокук бозулар турында эшләрне карарга һәм мондый бозуларны бетерү буенча чаралар күрергә;

5) җинаять билгеләре буенча җинаять эшләре кузгату турында мәсьәләне хәл итү өчен вәкаләтле органнарга лицензия таләпләре бозылуга бәйле материалларны җибәрергә;

6) үзләренә карата тикшерү үткәрелә торган юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән граждани-хокукый һәм хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаган һәм тикшерелә торган затларның аффилир затлары булмаган экспертларны, эксперт оешмаларын юридик затларны, шәхси эшкуарларны урынга чыгып тикшерүләр уздыруга җәлеп итәргә;

7) 294-ФЗ номерлы федераль законның 8.2 статьясындагы 5-7 өлешләре нигезендә зарури таләпләр бозылуга юл куймау турында кисәтүләр бирергә.

1.7. Лицензия контролен гамәлгә ашырганда ТР ДТИ вазыйфаи затлары түбәндәгеләрне бурычлы:

1) лицензия таләпләрен бозуларны кисәтү, ачыклау һәм чикләү буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә тапшырылган вәкаләтләрне үз вакытында һәм тулы дәрәҗәдә башкарырга;

2) Россия Федерациясе законнарын, үзләренә карата тикшерү уздырыла торган юридик затның, шәхси эшкуарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен сакларга;

3) ТР ДТИ җитәкчесенең, ТР ДТИ җитәкчесе урынбасарының билгеләнүе нигезендә тикшерү уздыру турында әмере нигезендә аны уздырырга;

4) тикшерүне бары тик хезмәт вазыйфаларын үтәү вакытында гына, урынга чыгып тикшерүне бары тик хезмәт таныкларын, ТР ДТИ җитәкчесенең, ТР ДТИ җитәкчесе урынбасарының әмере күчермәсен һәм, 294-ФЗ номерлы федераль законның 10 статьясының 5 өлешендә каралган очракта, тикшерү уздыруның килештерелүе турында документ күчермәсен күрсәтеп кенә үткәрергә;

5) юридик затның җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерүне үткәргәндә катнашуына һәм тикшерү предметына кагылышлы мәсьәләләрдә аңлатмалар бирүенә каршы килмәү;

6) тикшерүне үткәргәндә катнашучы юридик зат җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерү предметына кагыла торган мәгълүматларны һәм документларны бирергә;

7) юридик зат җитәкчесен, башка вазыйфаи затын яисә вәкаләтле вәкилен, шәхси эшкуарны, аның вәкаләтле вәкилен тикшерү нәтиҗәләре белән таныштырырга;

8) юридик зат җитәкчесен, башка вазыйфаи затын яисә вәкаләтле вәкилен, шәхси эшкуарны, аның вәкаләтле вәкилен ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынган документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән таныштырырга;

9) ачыкланган бозу фактлары буенча күрелә торган чараларны билгеләгәндә әлеге чараларның бозуларның авырлыгына, аларның гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренә), Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей предметларына һәм музей коллекцияләренә, Россия Федерациясе Архив фондының аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль документларына,

махсус тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияте булган, илкүләм китапханә фонды составына керә торган документларга, дәүләт иминлегенә, табигый һәм техноген характерлы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килүгә булган потенциаль хәтәрлелегенә туры килүен исәпкә алырга, шулай ук гражданнарның, шул исәптән шәхси эшкуарларның, юридик затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен нигезсез чикләүгә юл куймаска;

10) юридик затлар, шәхси эшкуалар тарафыннан шикаять белдерелгәндә үз гамәлләренең нигезле булуын Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә дәлилләргә;

11) тикшерү уздыруның 294-ФЗ номерлы федераль законда һәм 473-ФЗ номерлы федераль законның 24 статьясында билгеләнгән срокларын сакларга;

12) юридик заттан, шәхси эшкуардан Россия Федерациясе законнарында тапшырылуы каралмаган документларны һәм башка белешмәләрне таләп итмәскә;

13) урынга чыгып тикшерү үткәрә башлар алдыннан юридик зат җитәкчесенең, бүтән вазыйфаи затының яисә вәкаләтле вәкиленең, шәхси эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең гозере буенча аларны шушы Регламент нигезләмәләре белән таныштырырга;

14) юридик затта, шәхси эшкуарда булган очракта, урынга чыгып үткәрелгән тикшерү турында тикшерүләрне исәпкә алу журналында теркәргә (тикшерүләрне исәпкә алу журналының үрнәк рәвеше Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган).

1.8. Лицензия контролен гамәлгә ашырганда ТР ДТИ вазыйфаи затлары түбәндәгеләргә хокуклы түгел:

1) ТР ДТИ вәкаләтләренә карамый торган лицензия таләпләренең үтәлүен тикшерергә;

2) СССР һәм РСФСР башкарма хакимият органнары норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләр үтәлешен, шулай ук кулланылышы Россия Федерациясе законнарында каралмаган норматив документларның таләпләре үтәлешен тикшерергә;

3) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарылмаган лицензия таләпләренең һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрнең үтәлешен тикшерергә;

4) тикшерү уздырганда лицензиатның, лицензия алырга теләүченең җитәкчесе, бүтән вазыйфаи заты яисә аның вәкаләтле вәкиле булмаган очракта, планлы яисә урынга чыгып планнан тыш тикшерүне гамәлгә ашырырга, мондый тикшерү 294-ФЗ номерлы федераль законның 10

статьясының 2 өлешендәге 2 пунктының «б» пунктчасында каралган нигез буенча уздырылган очрактан тыш;

5) тикшерү предметына кагылмый торган документларны, мәгълүматларны тапшыруны таләп итәргә, шулай ук мондый документларның төп нөсхәләрен алырга;

6) тикшерү үткәрү нәтиҗәсендә алынган һәм дәүләт, коммерция, хезмәт серен, закон белән саклана торган башка төрле серне тәшкил итүче мәгълүматны таратырга, Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан тыш;

7) тикшерү уздыру өчен билгеләнгән чорларны арттырырга;

8) тикшерелә торган затка аның хисабыннан контрольлек буенча чаралар үткәрү турында күрсәтмәләр яки тәкъдимнәр бирүне гамәлгә ашырырга;

9) юридик заттан, шәхси эшкуардан, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яисә дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалар карамагында булган рөхсәт документларын да кертеп, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән исемлеккә кертелүче документларны һәм (яки) мәгълүматларны тапшыруларын таләп итәргә;

10) юридик заттан, шәхси эшкуардан тикшерүне үткәрә башлау датасына кадәр документлар, мәгълүматлар тапшыруны таләп итәргә. ТР ДТИ, тикшерү уздыру турында күрсәтмә яисә боерык кабул иткәннән соң, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында кирәкле документларны һәм (яки) мәгълүматларны соратырга хокуклы.

## Лицензия контроле буенча чаралар гамәлгә ашырыла торган затларның хокуклары һәм бурычлары

1.9. Тикшерү уздырылганда юридик зат җитәкчесенең, башка вазыйфаи затының яки вәкаләтле вәкиленең, шәхси эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең хокуклары:

1) тикшерүне үткәргәндә турыдан-туры катнашырга, тикшерү предметына кагыла торган мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә;

2) ТР ДТИ, аның вазыйфаи затларыннан тикшерү предметына кагыла торган һәм бирелеше 294-ФЗ номерлы федераль законда каралган мәгълүматларны алырга;

3) документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән эш итүче бүтән дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарының яисә җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалардан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында ТР ДТИ тарафыннан

алынган документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән танышырга;

4) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында сорала торган документларны һәм (яисә) мәгълүматларны ТР ДТИ үз ихтыяры белән тапшырырга;

5) тикшерү нәтиҗәләре белән танышырга һәм тикшерү актында тикшерү нәтиҗәләре белән үзенең танышуы, алар белән, шулай ук ТР ДТИ вазыйфаи затларының аерым гамәлләре белән ризалашуы яки ризалашмавы турында күрсәтергә;

6) тикшерүне үткәргәндә ТР ДТИ вазыйфаи затларының тикшерелүче затның хокуклары бозылуга китергән гамәлләренә (гамәл кылмауларына) Россия Федерациясе законнары нигезендә административ һәм (яки) суд тәртибендә шикаять белдерергә;

7) Россия Федерациясе Президенты каршындагы Шәхси эшкуарларның хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилне яисә Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Шәхси эшкуарларның хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилне тикшерүдә катнашуга җәлеп итәргә.

1.10. Юридик зат җитәкчесенең, аның башка вазыйфаи затының яки вәкаләтле вәкиленең, шәхси эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең тикшерү уздырганда бурычлары:

1) лицензия таләпләрен үтәү буенча чаралар оештыру һәм үткәрү өчен җаваплы җитәкченең йә вәкаләтле затларның булуын тәэмин итәргә;

2) күчмә тикшерү уздыручы ТР ДТИ вазыйфаи затларына, әгәр күчмә тикшерү үткәрелмәгән булса, күчмә тикшерүнең максатлары, бурычлары һәм предметы белән бәйле документлар белән танышу мөмкинлеген бирергә;

3) лицензиат тарафыннан кулланыла торган җиһазга лицензиат тарафыннан кулланыла торган бинага, төзелмәләргә, корылмаларга, бүлмәләргә лицензиат тарафыннан кулланыла торган территориягә экспертларны, эксперт оешмалары вәкилләрен чыгып тикшерү уздыручы вазыйфаи затларны, эксперт оешмалары вәкилләрен чыгып тикшерүне тәэмин итәргә;

4) документлар буенча тикшерү уздырганда күрсәтелгән документлар мөһер (ул булса) белән таныкланган күчермәләр рәвешендә һәм шәхси эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиле, җитәкче, юридик затның башка вазыйфаи затының имзасы белән тапшырыла. Юридик зат, шәхси эшкуар гарызнамәдә күрсәтелгән документларны көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документлар рәвешендә дә тапшырырга хокуклы;

5) тикшерүләр үткәрүгә комачауламаска;

6) тикшерүләрдән качмаска;

7) лицензия таләпләрен бозуларны бетерү турында вазыйфаи затларның күрсәтмәләрен билгеләнгән срокта үтәргә.

**Дәүләт функциясен үтәү нәтиҗәләрен тасвирлау**

1.11. Дәүләт функциясен үтәү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

1) тикшерү нәтиҗәләре буенча:

а) тикшерү нәтиҗәләре турында, шул исәптән ачыкланган лицензия таләпләрен бозу очраклары турында да, белешмәләрне үз эченә алган, әлеге Регламентка 1 нче кушымта нигезендәге форма буенча ике нөсхәдә төзелгән тикшерү акты (тикшерү актының бер төр үрнәге Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган);

б) 294-ФЗ номерлы федераль законның 13.3 статьясы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 415 номерлы карары нигезендә Тикшерүләрнең бердәм реестрына кертелгән тиешле мәгълүмат;

в) РФ Хөкүмәтенең 482 номерлы карары нигезендә «Контроль (күзәтчелек) эшчәнлеген автоматлаштыру буенча бер төр болыт чишелеше» дәүләт мәгълүмат системасына кертелгән тиешле мәгълүмат;

г) тикшерүләр журналында (булган очракта) урынга чыгып уздырылган тикшерү турында язу (тикшерүләрне исәпкә алу журналының рәвеше РФ Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган);

2) лицензия таләпләрен бозу, административ хокук бозу составы билгеләре ачыкланган очракта:

а) тикшерү актына кушымта булып торган лицензия таләпләрен бозу очракларын бетерү турында күрсәтмә (алга таба – күрсәтмә) (әлеге Регламентка 2 нче кушымта нигезендәге форма буенча);

б) Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 7.22, 7.23 статьяларында, 7.23.2 статьясының 1 өлешендә, 7.23.3 статьясында, 9.16 статьясының 4 һәм 5 өлешләрендә, 19.19.2 статьясының 1 өлешендә, 14.1.3 статьясында, 19.5 статьясының 24 өлешендә каралган хокук бозулар турында беркетмә (әлеге Регламентка 3 нче кушымтага ярашлы форма буенча) һәм Татарстан Республикасының баш дәүләт торак инспекторы, аның урынбасарлары тарафыннан каралган административ хокук бозу (Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 23.55 статьясы) турындагы эш буенча карар;

Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 7.23.2, 7.23.3 статьяларында (дисквалификацияләү кулланылган очракта), 14.1.3

статьясында (дисквалификацияләү кулланылган очракта), 13.19.2 статьясының 2 өлешендә, 7.32.2 статьясында, 19.4 статьясының 1 өлешендә, 19.5 статьясының 1 һәм 24 өлешләрендә, 19.6, 19.7, 19.7.11 статьяларында каралган административ хокук бозулар турында беркетмә (әлеге Регламентка 3 нче кушымтага ярашлы форма буенча) һәм судья (җәмәгать судьясы) тарафыннан каралган административ хокук бозу (Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 23.1 статьясы, 28.3 статьясының 2 өлешендәге 69 пункты) турындагы эш буенча карар;

3) лицензиатларның белән бәйләнешкә кермичә уздырылган контрольлек чарасы арышында лицензия таләпләрен бозарга җыену яки бозу билгеләре турында белешмәләр алынган очракта:

а) 294-ФЗ номерлы федераль законның 8.2 статьясындагы 5-7 өлешләре нигезендә лицензиатка бирелгән лицензия таләпләрен бозуга юл куймау турында кисәтү;

б) зарурлык булганда планнан тыш тикшерү билгеләү турында карар чыгару өчен ачыкланган хокук бозулар турындагы мәгълүмат белән ТР Дәүләт торак инспекциясе башлыгына, ТР Дәүләт торак инспекциясе башлыгы урынбасарына җибәрелгән, нигезле йогынты акты;

4) ТР Дәүләт торак инспекциясе хәл итми торган мәсьәләләргә кагылышлы хокук бозулар ачыкланган очракта:

федераль башкарма хакимият органнарына, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарына, административ хокук бозу турында эш кузгатуга вәкаләтле органнарга, хокук саклау органнарына җибәрелгән лицензия таләпләрен бозу турындагы мәгълүмат, материалар.

## 2. ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕН ҮТӘҮ ТӘРТИБЕНӘ КАРАТА ТАЛӘПЛӘР

### 2.1. Дәүләт функциясенең үтәлеше турында мәгълүмат бирү тәртибе

2.1.1. ТР Дәүләт торак инспекциясе урнашкан урын (почта адресы): 420111, Казан шәһәре, Б. Красная урамы, 15/9.

Җәмәгать транспортында «Ирек мәйданы» тукталышына кадәр килергә:

автобуслар № 22, 28, 28а, 52, 89;

троллейбуслар № 7, 20, 21;

метро (якындагы «Кремль» станциясе).

ТР Дәүләт торак инспекциясенең эш графигы: һәр көнне, шимбә һәм якшәмбедән тыш, дүшәмбе-пәнҗешәмбе 8.30 сәгатьтән 17.30 сәгатькә кадәр,

җомга 8.30 сәгатьтән 16.15 сәгатькә кадәр, төшке аш 12.00 сәгатьтән 12.45 сәгатькә кадәр.

Бәйрәм алды көннәрендә ТР ДТИ эш вакыты бер сәгатькә кими һәм бер сәгатькә иртәрәк тәмамлана.

Кертү пропуск һәм (яки) шәхесне таныклый торган документ ярдәмендә.

ТР ДТИнең дәүләт функциясен үтәү мәсьәләләре буенча мәгълүмат җиткерелә торган телефон номеры: 236-94-45.

Дәүләт функциясен гамәлгә ашыручы ТР ДТИ структур бүлекчәләренең урнашкан урыны турындагы мәгълүмат 1 нче таблицада китерелгән.

**1 таблица ТР ДТИнең дәүләт функциясен гамәлгә ашыручы структур бүлекчәләре турында белешмәләр**

| Территориаль орган | Адрес | Хезмәт күрсәтә торган территорияләре | Телефон |
|---|---|---|---|
| Альметьевская зональная жилищная инспекция | 423450, Әлмәт ш., Ленин ур., 47 | Әлмәт, Мөслим, Сарман муниципаль районнары | 8 (8553) 45-77-75 |
| Бөгелмә зонасы торак инспекциясе | 423200, Бөгелмә ш., Гафиатуллин ур., 18 | Азнакай, Баулы, Бөгелмә, Лениногорск, Чирмешән, Ютазы муниципаль районнары | 8 (85594) 6-05-45 |
| Алабуга зонасы торак инспекциясе | 423630, Алабуга ш., Пролетар ур., 46 | Әгерже, Алабуга, Мамадыш, Менделеевск муниципаль районнары | 8 (85557) 3-10-77 |
| Чаллы зонасы торак инспекциясе | 423802, Чаллы ш., ГЭС, 8/7 «Б» й., ком. 708 | Чаллы шәһәр округы, Актаныш, Минзәлә, Тукай муниципаль районнары | 8 (8552) 71-38-42 |
| Түбән Кама зонасы торак инспекциясе | 423570, Түбән Кама ш., Төзүчеләр проспекты ур., 6а | Зәй, Түбән Кама, Яңа Чишмә муниципаль районнары | 8 (8555) 42-37-33 |
| Чистай зонасы | 422980, | Алексеевск, Әлки, | 8 (84342) |

| | | | |
|---|---|---|---|
| торак инспекциясе | Чистай ш., Ленин ур., 1 | Аксубай, Нурлат, Спас, Чистай муниципаль районнары | 5-05-13 |
| Казан шәһәре торак инспекциясе (КШТИ) | 420080, Казан ш., Декабристлар ур., 179 | Казан шәһәр округы | 8 (843) 555-69-01 |
| Үзәк инспекторлык бүлеге | 420111, Казан ш., Б. Красная, 15/9 | Апас, Арча, Әтнә, Балтач, Буа, Югары Ослан, Биектау, Чүпрәле, Зеленодольск, Кайбыч, Кама Тамагы, Кукмара, Лаеш, Питрәч, Балык Бистәсе, Саба, Тәтеш, Теләче муниципаль районнары | 8 (843) 236-97-54 |

2.1.2. Дәүләт функциясен гамәлгә ашыру тәртибе турында мәгълүмат түбәндәгечә бирелә:

ТР ДТИ рәсми сайтында (https://gji.tatarstan.ru);

ТР Дәүләт торак инспекциясенә телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

ТР ДТИ язмача мөрәҗәгать итеп (шул исәптән электрон документ формасында электрон почта адресына: tatgi@tatar.ru).

2.1.3. ТР ДТИ сайтында түбәндәге мәгълүмат урнаштырыла:

ТР ДТИ еллык планы (алга таба - Тикшерүләр планы);

ТР ДТИ үткәргән тикшерүләр нәтиҗәләре турында мәгълүмат;

кушымталары белән бергә әлеге Регламент тексты;

дәүләт функциясе үтәлешен регламентлаучы норматив хокукый актлар;

дәүләт функцияләрен үтәү тәртибенең кыскача тасвирламасы;

ТР ДТИ эш графигы;

ТР ДТИ почта адресы;

дәүләт функцияләрен үтәү мәсьәләләре буенча мәгълүмат бирү гамәлгә ашырыла торган телефон номерлары;

дәүләт функцияләрен башкаручы ТР ДТИ вазыйфаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерү тәртибе;

бозуларны кисәтүнең ел саен раслана торган программасы;

үтәлешен бәяләү лицензия контроленең предметы булган лицензия таләпләрен үз эченә ала торган норматив хокукый актларның яисә аларның аерым өлешләренең исемлеге, шулай ук тиешле норматив хокукый актларның текстлары;

лицензия таләпләрен үтәү мәсьәләләре буенча, шулай ук лицензия таләпләрен үтәү буенча бастырып чыгарылган кулланмалар турында мәгълүмат, семинарлар һәм конференцияләр үткәрелүе, массакүләм мәгълүмат чараларында аңлату эшләре турында белешмәләр, бүтән ысуллар белән урнаштырылган бүтән мәгълүматлар турында белешмәләр. Лицензия таләпләре үзгәртелгән очракта, гамәлдәге актларга кертелгән үзгәрешләрдәге лицензия таләпләрен билгели торган яңа норматив хокукый актларның эчтәлеге, аларның гамәлгә керү вакытлары һәм тәртибе турында аңлатмалар, шулай ук лицензия таләпләрен кертүгә һәм аларның үтәлешен тәэмин итүгә юнәлдерелгән, зарури оештыру, техник чараларны үткәрү турында киңәшләр урнаштырыла;

лицензия контролен гамәлгә ашыру тәҗрибәсен гомумиләштерү (елга бер мәртәбәдән ешрак түгел), юридик затлар, шәхси эшкуарлар тарафыннан лицензия таләпләренең бозылуына юл куелмау максатларында күрелергә тиешле чаралар буенча киңәшләр белән, мондый бозуларның иң еш очрый торган очракларын күрсәтеп.

971 номерлы ТР МК карары белән расланган криетрияләргә ярашлы рәвештә югары һәм шактый куркынычлылык категориясенә кертелгән лицензия контроле объектлары турында тиешле мәгълүмат.

2.1.4. ТР ДТИ административ бинасының беренче катының үткәрү пунктында урнашкан мәгълүмат стендында түбәндәге мәгълүмат урнаштырыла:

вазыйфаи затларның телефон номерлары;

кушымталары белән бергә әлеге Регламент тексты;

дәүләт функциясе үтәлешен регламентлаучы норматив хокукый актлар;

ТР ДТИ эш графигы;

ТР ДТИ почта адресы;

зонага караган торак инспекцияләренең урнашу урыны;

дәүләт функциясен үтәү турында башка кирәкле мәгълүмат.

2.1.5. Телефон элемтәсе аша түбәндәге мәгълүмат бирелергә мөмкин:

дәүләт функцияләрен үтәү мәсьәләләрен регламентлаштыручы норматив хокукый актлар турында;

дәүләт функциясен үтәү тәртибе турында;

дәүләт функциясен үтәү чорлары турында;

ТР ДТИ һәм зона торак инспекцияләренең урнашу урыннары һәм эш графигы турында;

ТР ДТИ сайтының адреслары турында;

дәүләт функциясен үтәү барышы турында.

2.1.6. Башка мәсьәләләр буенча мәгълүмат бары тиешле язма мөрәҗәгать нигезендә генә бирелә.

## 2.2. Лицензиатлардан лицензия контроле чараларын үткәргән өчен түләү алуга юл куймау

2.2.1. Лицензиаттан лицензия контроле чараларын үткәргән һәм дәүләт функцияләрен башкаруда катнашучы экспертлар һәм эксперт оешмалары хезмәтләре өчен түләү алу рөхсәт ителми.

## 2.3. Дәүләт функциясен үтәү вакыты һәм ешлыгы

2.3.1. Документар тикшерүләрнең дә (планлы, планнан тыш), урынга чыгып тикшерүләрнең дә (планлы, планнан тыш) һәркайсының озынлыгы (тикшерүне башлау датасыннан алып тикшерү нәтиҗәләре буенча акт төзү датасына кадәр) 20 (егерме) эш көненнән артык була алмый.

Әгәр тикшерелә торган зат кече эшкуарлык субъекты булып тора икән, планлы урынга чыгып тикшерүләрне уздыруның гомуми срогы бер елга кече предприятие өчен 50 (илле) сәгатьтән һәм микропредприятие өчен 15 (унбиш) сәгатьтән артык була алмый.

Кече эшкуарлык субъектына урынга чыгып планлы тикшерү уздырганда ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында документлар һәм (яисә) мәгълүматлар алу зарурлыгы булган очракта, тикшерүне уздыру ТР ДТИ башлыгы, ТР ДТИ җитәкчесе урынбасары тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне гамәлгә ашыру өчен кирәкле срокка, ләкин ун эш көненнән артып китмәгән чорга туктатып торылырга мөмкин. Тикшерү үткәрүне яңадан туктатып тору рөхсәт ителми.

Тикшерү үткәрүне туктатып тору чоры гамәлдә булганда кече эшкуарлык субъекты территориясендә, биналарында, төзелмәләрендә,

корылмаларында, бүлмәләрендә, бүтән объектларында ТР ДТИ күрсәтелгән тикшерүгә бәйле гамәлләре дә туктатып торыла.

Искәрмәле, катлаулы һәм (яисә) озак вакытлы тикшеренүләрне, махсус экспертизаларны һәм тикшерүләрне үткәрү зарурлыгына бәйле булган очракларда, ТР ДТИнең урынга чыгып планлы тикшерүне үткәрүче вазыйфаи затларының нигезләнгән тәкъдимнәре ТР ДТИ җитәкчесе тарафыннан озынайтылырга мөмкин, ләкин 20 (егерме) эш көненнән дә артыграк булган чорга түгел, кече предприятиеләр өчен иң күбе – 50 (илле) сәгатькә, микропредприятиеләр өчен иң күбе – 15 (унбиш) сәгатькә.

Алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре резидентларына карата гамәлгә ашырыла торган тикшерүләрне үткәрү сроклары 473-ФЗ номерлы федераль законның 24 статьясы нигезендә билгеләнә.

2.3.2. Планлы тикшерүләр Татарстан Республикасында үзләренә карата 856 номерлы ТР МК карары белән расланган куркыныч юнәлешле алым кулланыла торган төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) төрләре исемлегенә ярашлы рәвештә куркыныч-юнәлешле алым кулланып уздырыла.

Лицензия контролен гамәлгә ашырганда куркыныч-юнәлешле алымны куллану максатларында юридик затларның, шәхси эшкуарларның эшчәнлеге ТР ДТИ җитәкчесе (җитәкче урынбасары ) карары нигезендә 971 номерлы ТР МК карары белән расланган критерияләргә ярашлы рәвештә билгеле бер куркынычлылык категориясенә кертелергә тиеш.

Юридик затлар, шәхси эшкуарлар тарафыннан гамәлгә ашырыла торган эшчәнлекне билгеле бер куркынычлылык категориясенә кертү турында карар булмаган очракта, юридик затларның, шәхси эшкуарларның эшчәнлеге түбән дәрәҗәдәге куркынычлылык категориясенә кертелгән булып санала.

Юридик зат яки шәхси эшкуар 806 номерлы РФ Хөкүмәте карарында билгеләнгән тәртиптә үз эшчәнлекләренә элегрәк бирелгән куркынычлылык категориясен үзгәртү турында ТР ДТИ гариза бирергә хокуклы.

## 2.4. Тикшерүләр үткәрү өчен нигезләр

2.4.1. Лицензиатка планлы тикшерү билгеләнгән тәртиптә ТР ДТИ тарафыннан эшләнгән һәм расланган Тикшерүләр планы нигезендә һәм аңа туры китереп уздырыла.

Лицензиатларга планлы тикшерүләр, критерияләргә ярашлы рәвештә алар тарафыннан гамәлгә ашырылучы эшчәнлеккә беркетелгән куркынычлылык категориясенә карап, түбәндәге ешлыкта уздырыла:

югары дәрәҗәле хәвефлелек категориясе өчен – ике елга бер тапкыр; шактый куркынычлылык категориясе өчен – өч елга бер тапкыр;

уртача куркынычлылык категориясе өчен – алты елга бер тапкыр һәм сигез елга кимендә бер тапкыр;

куркынычлылыкның түбән категориясе өчен – планлы тикшерүләр үткәрелми.

Лицензиатларны планлы тикшерүләр үткәрелә:

1) лицензия бирү турында карар кабул ителгән көннән бер елдан да иртәрәк булмаган чорда;

2) әлеге пунктның икенче-алтынчы абзацларында күрсәтелгән ешлыкка ярашлы рәвештә.

2019 елның 1 гыйнварыннан башлап 2020 елның 31 декабренә кадәрге чорда үзләре турында белешмәләр кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы федераль законның 4 статьясы нигезләмәләренә ярашлы нигездә кече эшкуарлык субъектларына кертелгән юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга карата планлы тикшерүләр 294-ФЗ номерлы федераль законның 26.2 статьясы таләпләренә ярашлы рәвештә оештырыла һәм үткәрелә.

2.4.2. Лицензиатны планнан тыш урынга чыгып тикшерү түбәндәге нигезләр буенча үткәрелә:

1) ТР ДТИ тарафыннан элегрәк бирелгән лицензия таләпләре бозылуны юкка чыгару турында күрсәтмәнең лицензиат тарафыннан үтәү вакыты узу;

2)ТР ДТИ лицензиатның лицензия таләпләрен җитди бозу фактлары турында гражданнардан, шул исәптән шәхси эшкуарлардан, юридик затлардан мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан мәгълүматлар килү;

3) ТР ДТИ күрсәтмәсенең вакытыннан алда үтәлү фактын билгеләү максатларында ТР ДТИ тарафыннан планнан тыш урынга чыгып тикшерү уздыру турында лицензиатның үтенеч язуы булуы;

4) ТР ДТИ юридик заттан яисә шәхси эшкуардан хокукый статус, эшчәнлекнең аерым төрләрен гамәлгә ашыру хокукына махсус рөхсәт (лицензия) яисә юридик әһәмияткә ия булган башка төрле аерым эшчәнлекне гамәлгә ашыру хокукына махсус рөхсәт (лицензия) бирү турында гариза килүе, әгәр юридик затка, шәхси эшкуарга тиешле планнан тыш тикшерүне уздыру хокукый статус, махсус рөхсәт (лицензия) бирү, рөхсәт бирү (килештерү) кагыйдәләрендә каралган булса (тикшерүләр прокуратура органнары белән килештермичә һәм планнан тыш тикшерүне уздыру турында лицензиатка алдан хәбәр иткәннән соң уздырыла);

5) ТР ДТИ вазыйфаи затының дәлилле йогынты акты, – юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән бәйләнешкә кермичә үткәрелгән контрольлек чаралары, гражданнардан, шул исәптән шәхси эшкуарлардан, юридик затлардан ТР ДТИ килгән мөрәҗәгатьләрне һәм гаризаларны, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан алынган мәгълүматларны карап тикшерү яки беренчел тикшерү нәтиҗәләрен анализлау нәтиҗәсендә, – түбәндәге фактлар турында (тикшерүләр прокуратура органнары белән килештереп, планнан тыш тикшерүне уздыру турында лицензиатка алдан хәбәр итмичә уздырыла):

а) гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренә), Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей предметларына һәм музей коллекцияләренә, Россия Федерациясе Архив фондының аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль документларына, махсус тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия булган, илкүләм китапханә фонды составына керүче документларга, дәүләт иминлегенә зарар китерү куркынычы, шулай ук табигый һәм техноген холыклы гадәттән тыш хәлләр куркынычы барлыкка килү;

б) гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян килү, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренә), Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән музей предметларына һәм музей коллекцияләренә, Россия Федерациясе Архив фондының аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль документларына, махсус тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия булган, илкүләм китапханә фонды составына керүче документларга, дәүләт иминлегенә зарар килү, шулай ук табигый һәм техноген холыклы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү;

6) 294-ФЗ номерлы федераль законның 8.1 статьясының 1 һәм 2 өлешләрендә күрсәтелгән дәүләт контроле (күзәтчелеге) төрләрен гамәлгә ашырганда, юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән хезмәттәшлек итмичә чаралар уздырганда юридик затның, шәхси эшкуарның эшчәнлегендә ТР ДТИ тарафыннан расланган куркыныч индекаторы буенча аларга туры килү яисә алардан тайпылу дәүләт контроле (күзәтчелеге) төре турында нигезләмәдә каралганча планнан тыш тикшерүне уздыру өчен нигез булып торган параметрлар ачыклану (тикшерүләр прокуратура органнары белән килештереп һәм планнан тыш тикшерүне уздыру турында лицензиатка алдан хәбәр итеп уздырыла);

7) Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте йөкләмәләренә туры китереп һәм прокурорның прокуратура органнарына килгән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнар үтәлешен күзәтү кысаларында планнан тыш тикшерү үткәрү турындагы таләбе нигезендә

чыгарылган ТР ДТИ башлыгы күрсәтмәсе (тикшерүләр прокуратура органнары белән килештермичә һәм планнан тыш тикшерүне уздыру турында лицензиатка алдан хәбәр итеп уздырыла).

2.4.3. Юридик затларны, шәхси эшкуарларны әлеге Регламентның 2.4.2 пунктының 1, 3 пунктчаларында каралган нигезләр буенча планнан тыш тикшерү прокуратура органнары белән килештермичә һәм планнан тыш тикшерү уздыру турында лицензиатка алдан хәбәр итмичә уздырыла.

2.4.4. Лицензия алырга теләүчегә тикшерү уздыру нигезе булып лицензия бирү турында ТР ДТИ гариза килүе тора.

2.4.5. Юридик затларга, шәхси эшкуарларга планнан тыш урынга чыгып тикшерү ТР ДТИ тарафыннан әлеге Регламентның 2.4.2 пунктындагы 2, 5 һәм 6 пунктчаларында күрсәтелгән нигезләр буенча, мондый юридик затларның, шәхси эшкуарларның эшчәнлекләре гамәлгә ашырылу урыны буенча, прокуратура органы белән килештергәннән соң үткәрелергә мөмкин.

2.4.6. Юридик затларны, шәхси эшкуарларны әлеге Регламентның 2.4.2 пунктының 2 һәм 5 пунктчаларында каралган нигезләр буенча планнан тыш тикшерү лицензиатка планнан тыш тикшерү уздыру турында алдан хәбәр итмичә уздырыла.

2.4.7. ТР ДТИ мөрәҗәгать итүченең затын билгеләргә мөмкинлек бирми торган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, шулай ук әлеге Регламентның 2.4.2 пунктының 5 пунктчасында күрсәтелгән фактлар турында белешмәләре булмаган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булып хезмәт итә алмый. Әгәр мөрәҗәгатьтә яки гаризада бәян ителгән мәгълүмат, шушы Регламентның 2.4.2 пунктындагы 5 пунктчасы нигезендә планнан тыш тикшерү үткәрүнең нигезе була алса, ТР ДТИ вазыйфаи заты, аның мөрәҗәгатьнең яки гаризаның авторына карата нигезле шикләре булганда, мөрәҗәгать итүче затны билгеләү буенча гакыллы чаралар күрергә бурычлы. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон документлар рәвешендә җибәрелгән мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, аларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан бары тик бердәм идентификация һәм аутентификация системасында мөрәҗәгать итүченең мәҗбүри авторлаштырылуын күздә тотучы мәгълүмат-коммуникация технологияләре чараларыннан файдаланып җибәрелгән булуы шарты белән генә, планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булып хезмәт итә ала.

2.4.8. Беренчел тикшерү нәтиҗәләре буенча лицензия таләпләре бозылуга юл куйган затлар ачыкланганда, лицензия таләпләренең бозылуы турында яисә шушы Регламентның 2.4.2 пунктының 5 пунктчасында күрсәтелгән фактлар турында җитәрлек күләмдә мәгълүматлар алынганда, ТР ЭТРМ вәкаләтле вазыйфаи заты, шушы Регламентның 2.4.2 пунктының 1, 4, 5, 6 һәм 7 пунктчаларында күрсәтелгән нигезләр буенча, планнан тыш тикшерү үткәрү турында дәлилле йогынты актын әзерли. Беренчел тикшерү

нәтиҗәләре буенча юридик затны, шәхси эшкуарны җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрелми.

2.4.9. ТР ДТИ башлыгы, ТР ДТИ башлыгы урынбасары карары нигезендә, әгәр дә тиешле тикшерүне башлаганнан соң, аны оештыру өчен нигез булган мөрәҗәгатьнең яки гаризаның аноним булуы ачыкланса, яисә мөрәҗәгатьтә яки гаризада белә торып ялган белешмәләр булуы ачыкланса, беренчел тикшерү, планнан тыш тикшерү туктатыла.

2.4.10. ТР ДТИ, әгәр гаризаларда, мөрәҗәгатьләрдә белә торып ялган белешмәләр күрсәтелсә, гражданиннан, шул исәптән юридик заттан, шәхси эшкуардан, аталган затлардан килгән гаризаларны, мөрәҗәгатьләрне карап тикшерүгә бәйле рәвештә, ТР ДТИ тарафыннан тотылган чыгымнарны түләттерү турында судка шикаять белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

### 2.5. Лицензия контролен турыдан-туры уздыра торган вазыйфаи затлар

Лицензия контролен уздыруны турыдан-туры түбәндәгеләр гамәлгә ашыра:

ТР ДТИ башлыгы;

ТР ДТИ башлыгы урынбасарлары;

ТР ДТИ җитәкчесе урынбасарлары – зональ торак инспекцияләре җитәкчеләре;

Казан шәһәре торак инспекциясе башлыгы урынбасары;

Яр Чаллы зонасы торак инспекциясе башлыгы урынбасары;

ТР ДТИ Үзәк инспекторлык бүлеге башлыгы;

ТР ДТИ Үзәк инспекторлык бүлеге башлыгы урынбасары;

ТР ДТИ торак фондын капиталь ремонтлауны тикшереп тору бүлеге башлыгы;

ТР ДТИ ТКХ өчен түләүләрнең нигезле булу-булмавын тикшерү бүлеге башлыгы;

торак күзәтчелеге һәм лицензия контроле бүлеге башлыгы;

тикшерүдә тоту-аналитика бүлеге башлыгы;

зональ торак инспекцияләрнең, ТР ДТИ Үзәк инспекторлык бүлегенең, ТР ДТИ торак фондын капиталь ремонтлауны тикшереп тору бүлегенең, ТР ДТИ ТКХ өчен түләүләрнең нигезле булу-булмавын тикшерү бүлегенең, торак күзәтчелеге һәм лицензия контроле бүлегенең, тикшерүдә тоту-

аналитика бүлегенең вазыйфаи затлары (дәүләт торак инспекторлары).

Лицензия контроле турыдан-туры ТР ДТИ башлыгы, ТР ДТИ башлыгы урынбасары боерыгы белән тикшерү уздыруга вәкаләт бирелгән вазыйфаи затлар тарафыннан гамәлгә ашырыла.

### 2.6. Лицензиатларның РФ Торак кодексын, 99-ФЗ номерлы федераль законны һәм 294-ФЗ номерлы Федераль законны бозган өчен җаваплылыгы

2.6.1. 294-ФЗ номерлы федераль закон бозылуга юл куйган, тикшерүләрне үткәрүгә нигезсез рәвештә каршы төшүче, тикшерүләрне үткәрүдән качып йөрүче һәм (яки) билгеләнгән чорларда ТР ЭТРМ зарури таләпләрнең ачыкланган бозуларын бетерү турында күрсәтмәсен үтәмәүче юридик затлар, аларның җитәкчеләре, бүтән вазыйфаи затлары яки вәкаләтле вәкилләре, шәхси эшкуарлар, аларның вәкаләтле вәкилләре Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы була.

2.6.2. Тикшерү үткәрү яисә мондый тикшерүдән читләшү буенча ТР ДТИ вазыйфаи затының законлы эшчәнлегенә каршы килгәндә, Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 19.4 ст. 1 өлеше буенча административ хокук бозу турында беркетмә төзелә, ул җәмәгать судьясына карауга җибәрелә.

2.6.3. Лицензияле таләпләрне бозуларны бетерү турындагы канунлы күрсәтмәне үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен, Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 19.5 ст. 24 өлеше буенча административ хокук бозу турында беркетмә төзелә, ул дөнья судьясына карауга җибәрелә.

### 2.7. Тикшерү барышында ТР ДТИ, аның вазыйфаи затларының җаваплылыгы

ТР ДТИ, аның вазыйфаи затлары, тикшерү уздырганда хокукка каршы гамәлләр кылып (гамәл кылмыйча) тиешле функцияләрне, хезмәт вазыйфаларын тиешенчә үтәмәгән очракта, Россия Федерациясе законнары нигезендә дисциплинар, адиминистратив яки җинаять җаваплылыгына тартылалар.

Россия Федерациясе законнарын бозуда гаепле ТР ДТИ вазыйфаи затларына карата күрелгән чаралар турында мондый чаралар күрелгән көннән соң ун көн эчендә ТР ДТИ язмача рәвештә хокуклары һәм (яки) законлы мәнфәгатьләре бозылган лицензиатка хәбәр итәргә бурычлы.

## 3. ЛИЦЕНЗИАТЛАРГА КУЕЛА ТОРГАН ЛИЦЕНЗИЯ ТАЛӘПЛӘРЕ

3.1. Үтәлеше тикшереп торыла торган, лицензиатларга, лицензия алырга теләүчеләргә карата белдерелүче лицензия таләпләренең исемлеге, аларны

билгеле торган норматив хокукый актлар исемлеге, тикшерү барышында лицензиатлар, лицензия алырга теләүчеләр тапшыра торган документлар исемлеге 2 нче таблицада китерелгән.

**2 нче таблица – Юридик затларга, шәхси эшкуарларга белдерелә торган лицензия таләпләре исемлеге**

| т/с | Лицензия контроле объектлары | Лицензия таләбенең тәгъбирләнеше | Лицензия таләбен билгели торган норматив хокукый акт | Лицензиатларга, лицензия алырга теләүчеләргә белдерелә торган документлар исемлеге |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Лицензиат, лицензия алырга теләүче | Россия Федерациясе территориясендә лицензиатның, лицензия алырга теләүченең юридик зат яисә шәхси эшкуар сыйфатында теркәлгән булуы | РФ Торак кодексының 193 ст. 1 өл. 1 п. | - |
| 2. | Лицензиат, лицензия алырга теләүче | Лицензия алырга теләүченең яисә лицензиатның фирма аталышы күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру хокукы алданрак барлыкка килгән лицензиатның фирма аталышы белән охшаш булмавы яисә бутау дәрәҗәсендә бер-берсенә туры килмәве | РФ Торак кодексының 193 ст. 1 өл. 1.1 п. | - |
| 3. | Лицензиат, лицензия алырга теләүче | Лицензиатның, лицензия алырга теләүченең вазыйфаи затында (күпфатирлы йорт белән идарә итүне гамәлгә ашыручы юридик затның бер кулдагы башкарма органында, юридик зат | РФ Торак кодексының 193 ст. 1 өл. 2 п. | Лицензиатның вазыйфаи затында (күпфатирлы йорт белән идарә итүне гамәлгә ашыручы юридик затның |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | җитәкчесендә яисә аның филиалында яисә шәхси эшкуарда, ә бер кулдагы башкарма орган вәкаләтләрен тапшыру турында шартнамә төзелгән очракта – мондый вәкаләтләр тапшырылган юридик затның бер кулдагы башкарма органында яисә шәхси эшкуарда) квалификация аттестатының булуы | | бер кулдагы башкарма органында, юридик зат җитәкчесендә яисә аның филиалында яисә шәхси эшкуарда, ә бер кулдагы башкарма орган вәкаләтләрен тапшыру турында шартнамә төзелгән очракта – мондый вәкаләтләр тапшырылган юридик затның бер кулдагы башкарма органында яисә шәхси эшкуарда) квалификация аттестатының копиясе булу |
| 4. | Лицензиат, лицензия | Лицензиатның вазыйфаи затында, лицензия алырга теләүченең | РФ Торак кодексының 193 | - |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | алырга теләүче | вазыйфаи затында икътисад өлкәсендәге җинаятьләр өчен, уртача авырлыктагы, авыр һәм аеруча авыр җинаятьләр өчен алынмаган яисә үтәлмәгән суд хөкеме булмавы | ст. 1 өл. 3 п. | |
| 5. | Лицензиат, лицензия алырга теләүче | Лицензиатның лицензиясе гамәлдән чыгарылган бер кулдагы башкарма орган функцияләрен гамәлгә ашыручы затлар, шулай ук лицензиат уставында яисә башка документларында күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне тиешенчә карап тотуны тәэмин итүгә карата таләпләрне үтәү өчен җаваплылык йөкләнгән һәм үзләренә карата квалификациясен алу рәвешендә административ җәза кулланылган затлар, лицензиясе гамәлдән чыгарылган һәм квалификациясен алу рәвешендә административ җәза билгеләнгән шәхси эшкуарлар реестрында лицензиатның вазыйфаи заты, лицензия алырга теләүченең вазыйфаи заты турында мәгълүматның булмавы | РФ Торак кодексының 193 ст. 1 өл. 4 п. | - |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 6. | Лицензиат, лицензия алырга теләүче | Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензияләрнең җыелма федераль реестрында лицензиатка, лицензия алырга теләүчегә элегрәк бирелгән лицензияне гамәлдән чыгару турында мәгълүмат булмавы | РФ Торак кодексының 193 ст. 1 өл. 5 п. | - |
| 7. | Лицензиат | Мәгълүмат урнаштыруга карата Россия Федерациясе Торак кодексының 161 статьясының 10.1 өлешендә билгеләнгән таләпләрнең үтәлүе | РФ Торак кодексының 193 ст. 1 өл. 6.1 п.<br>РФ Торак кодексының 161 ст. 10.1 өл. | - |
| 8. | Лицензиат | Әлеге йортта гомуми мөлкәтне тиешенчә карап тотуны тәэмин итә торган һәм сыйфаты техник регламентлар таләпләренә туры килергә тиешле һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту кагыйдәләрен үтәүче барлык хезмәтләрне күрсәтү һәм (яисә) эшләр башкару | РФ Торак кодексының 161 ст. 2.3 өл.<br>РФ Хөкүмәтенең 491 номерлы карары;<br>техник регламентлар | Күпфатирлы йорт белән идарә итүче оешманың йортта уртак мөлкәтне тиешенчә карап тоту буенча хезмәтләр күрсәтүче һәм эшләр башкаручы оешмалар белән шартнамәләре |
| 9. | Лицензиат | Йортның төзекләндерелү | РФ Торак | Күпфатирлы йорт |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | дәрәҗәсенә карап сыйфаты Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән күпфатирлы йортларда һәм торак йортларда милекчеләргә һәм биналардан файдаланучыларга коммуналь хезмәтләрне күрсәтү, күрсәтүне туктатып тору һәм чикләү кагыйдәләре, яисә, РФ Торак кодексының 157.2 статьясында каралган очракларда, инженерлык системаларының әзерлеген тәэмин итү таләпләренә җавап бирергә тиешле коммуналь хезмәтләрне күрсәтү. | кодексының 161 ст. 2.3 өл.<br>РФ Хөкүмәтенең 354 номерлы карары | белән идарә итүче оешманың ресурс белән тәэмин итүче оешмалар белән шартнамәләре |
| 10. | Лицензиат | Күпфатирлы йорт белән идарә итү шартнамәсе буенча бурычларны үтәү | РФ Торак кодексының 162 ст. 2 өл.; | Күпфатирлы йортлар белән идарә итү шартнамәләре |
| 11. | Лицензиат | Идарәче оешма, торак милекчеләре ширкәте, торак яки торак-төзелеш кооперативы идарәсе, башка төрле махсуслашкан кулланучылар кооперативы тарафыннан күпфатирлы йортта биналарның милекчеләр реестрын анда булган | РФ Торак кодексының 45 ст. 3.1 өл.,<br>Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | белешмәләргә карата билгеләнгән таләпләрне үтәп алып бару | лицензияләү турында нигезләмәнең 3 п. «в» пп. | |
| 12. | Лицензиат | Биналарның милекчеләренә яки башка затка аларның язмача формадагы мөрәҗәгате нигезендә, билгеләнгән таләпләрне үтәп, күпфатирлы йортта биналарның милекчеләре реестрын бирү | РФ Торак кодексының 45 ст. 3.1 өл., Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү турында нигезләмәнең 3 п. «в» пп. | |
| 13. | Лицензиат | Идарәче оешма күпфатирлы йорт белән идарә итү шартнамәсен үти башларга керешергә тиешле срокны үтәү | РФ Торак кодексының 162 ст. 7 өл., Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү турында нигезләмәнең 3 п. | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | «г» пп. | |
| 14. | Лицензиат | Россия Федерациясе субъектының лицензияләр реестрыннан күпфатирлы йорт турында белешмәләр төшереп калдырылган очракта РФ Торак кодексының 200 статьясында билгеләнгән күпфатирлы йорт белән идарә итү буенча лицензиат тарафыннан эшчәнлекне туктату (шул исәптән торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү хисаплауны һәм түләү алуны, кулланучыларга түләү документларын бирүне туктату, РФ Торак кодексының 200 статьясының 3 өлешендә каралган очраклардан тыш) тәртибен һәм срокларын саклау | РФ Торак кодексының 198 ст. 6 өл., Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү турында нигезләмәнең 3 п. «г» пп. | |
| 15. | Лицензиат, лицензия алырга теләүче | Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән башка төрле таләпләр | РФ Торак кодексының 193 ст. 1 өл. 7 п. | |

3.2. Юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар тарафыннан лицензия таләпләре бозылуны кисәтү, лицензия таләпләре бозылуга китерә торган сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны юкка чыгару максатларында ТР ДТИ ел саен үзе тарафыннан расланучы бозуларны профилактикалау программасы нигезендә лицензия таләпләре бозылны профилактикалау буенча чараларны гамәлгә ашыра.

3.3. Лицензия таләпләрен бозуга әзерләнүләр яисә бозу билгеләре турында юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән элемтәгә кермичә гамәлгә ашырыла торган контрольлек чараларын тормышка ашыру барышында ТР ДТИ алынган яисә килгән мөрәҗәгатьләрдә һәм гаризаларда (авторлыгы расланмаган мөрәҗәгатьләрдән һәм гаризалардан тыш) бәян ителгән белешмәләр, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан мәгълүматлар булганда, әгәр лицензия таләпләре бозылуның гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян китерүе, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренә), дәүләт иминлегенә зыян салуы, шулай ук табигый һәм техноген холыклы гадәттән тыш хәлләр барлыкка китерүе яисә күрсәтелгән нәтиҗәләрнең турыдан-туры куркынычын барлыкка китерүе турында дәлилләнгән белешмәләр булмаса һәм, әгәр дә юридик зат, шәхси эшкуар элегрәк тиешле таләпләрне бозган өчен җаваплылыкка тартылмаган булса, ТР ДТИ юридик затка, шәхси эшкуарга лицензия таләпләрен бозуның ярамаганлыгы турында кисәтү белдерә һәм юридик затка, шәхси эшкуарга лицензия таләпләренең үтәлүен тәэмин итү буенча чаралар күрергә һәм бу хакта мондый кисәтүдә билгеләнгән чорда ТР ДТИ хәбәр итүне тәкъдим итә.

3.4. Лицензия таләпләрен бозуның ярамаганлыгы турында кисәтү төзү һәм җибәрү, юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан мондый кисәтүгә ризасызлыклар тапшыру һәм аларны ТР ДТИ тарафыннан карау, юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан мондый кисәтүнең үтәлүе турында ТР ДТИ хәбәр итү РФ Хөкүмәтенең 166 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләргә ярашлы рәвештә гамәлгә ашырыла.

## 4. ТИКШЕРҮ БАРЫШЫНДА ЛИЦЕНЗИАТ ТАРАФЫННАН ТАПШЫРЫЛА ТОРГАН ДОКУМЕНТЛАР

Тикшерү үткәрүнең максатларына һәм бурычларына ирешү өчен лицензиат тарафыннан тапшырыла торган документларның исемлеге, шулай ук мондый документларның рәвешләрен раслый торган норматив хокукый актлар 3 нче таблицада китерелгән.

**3 нче таблица – Тикшерү үткәрүнең максатларына һәм бурычларына ирешү өчен лицензиат, лицензия алырга теләүче тарафыннан**

**тапшырыла торган документлар исемлеге**

| Тикшерүне уздыру өчен лицензиат, лицензия алырга теләүче тарафыннан тапшырыла торган документ | Документ рәвешен билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|
| 1. Гражданин шәхесен таныклаучы документлар (шәхси эшкуарлар өчен) | РФ Хөкүмәтенең 08.07.1997 N 828 карары |
| 2. Юридик затның, шәхси эшкуарның яисә гражданинның мәнфәгатьләрен белдерүче затның вәкаләтләрен раслаучы документлар | РФ Граждан кодексының 185 ст. |
| 3. Җитешсезлекләрне оператив юкка чыгаруга халыктан заявкаларны исәпкә алу журналы | Россия Дәүләт төзелеш агентлыгының 170 номерлы карарына 5 нче кушымта |
| 4. Күпфатирлы йорт белән идарә итү шартнамәсе | РФ Торак кодексының 162 ст. |
| 5. Торак йортлар белән идарә итүче оешманың эше турында еллык хисап | РФ Торак кодексының 162 ст. 11 өл. |
| 6.Торак йортлар белән идарә итүче оешманың коммуналь ресурслар белән тәэмин итүчеләр белән шартнамәсе | РФ Хөкүмәте карарының 354 номерлы карарының 13 пункты |
| 7. Юридик затның, шәхси эшкуарның дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контрольлек органнары тарафыннан уздырыла торган тикшерүләрне исәпкә алу журналы (булган очракта) | Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 нче боерыгына 4 нче кушымта |
| 8. Торак йортны эксплуатацияләүгә бәйле техник документация (йортның проекты, техник паспорты, йортны һәм (яки) торак урыннарны планлы һәм планнан тыш тикшерү актлары, йорт эче җылыту системаларын юдыру, басым астында ныклыкка тикшереп карау актлары, йортның кышкы шартларда эксплуатацияләүгә әзерлеге паспорты, ремонт эшләрен башкару план-графиклары һ.б.) | Россия Төзелеш министрлыгының 170 номерлы карары |

## 5. АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАЛАРНЫҢ (ГАМӘЛЛӘРНЕҢ) СОСТАВЫ, ЭЗЛЕКЛЕЛЕГЕ ҺӘМ АЛАРНЫ ҮТӘҮ ВАКЫТЛАРЫ, АЛАРНЫ ҮТӘҮ ТӘРТИБЕНӘ КАРАТА ТАЛӘПЛӘР, ШУЛ ИСӘПТӘН АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАЛАРНЫ (ГАМӘЛЛӘРНЕ) ЭЛЕКТРОН ФОРМАДА ДА ҮТӘҮ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Лицензия контроле лицензия таләпләре бозылуны профилактикалау буенча чараларны оештыру һәм уздыру (әлеге Регламентның 3.2-3.4 пунктлары), документар тикшерүләр һәм (яисә) урынга чыгып тикшерүләр формасында планлы һәм планнан тыш тикшерүләр оештыру һәм уздыру, мәгълүмат ачуга карата Россия Федерациясе Торак кодексының 161 статьясының 10.1 өлешендә билгеләнгән таләпләрнең лицензиат тарафыннан үтәлүен системалы рәвештә күзәтү, лицензия таләпләренең бозылуны чикләү һәм (яки) ачыкланган нәтиҗәләрен бетерү буенча Россия Федерациясе законнарында каралган чараларны күрү юлы белән, шулай ук юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән элемтәгә кермичә контрольлек чараларын гамәлгә ашыру юлы белән башкарыла.

Лицензиатларга карата планлы һәм планнан тыш тикшерүләр гамәлгә ашырыла, лицензия алырга теләүчеләр өчен планнан тыш тикшерүләр уздырыла.

Әлеге Регламент түбәндәге административ процедураларның үтәлүен күздә тота:

лицензиатка карата планлы документар тикшерү уздыру;

лицензиатка карата урынга чыгып планлы тикшерү уздыру;

лицензиатка, лицензия алырга теләүчегә карата планнан тыш документар тикшерү уздыру;

лицензиатка, лицензия алырга теләүчегә карата планнан тыш урынга чыгып тикшерү уздыру;

лицензиатлар белән элемтәгә кермичә контрольлек чаралары оештыру һәм уздыру.

Дәүләт функциясен үтәүнең блок-схемасы Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда рөхсәт ителә.

Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда дәүләт функциясен үтәүне туктатып тору рөхсәт ителә.

Алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре резидентларына карата лицензия контроле әлеге Регламент нигезендә һәм 473-ФЗ номерлы федераль законның 24 статьясында, РФ Хөкүмәтенең 1132 номерлы

карарында, Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 817 номерлы боерыгында билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

## 5.1. «Лицензиатка планлы документар тикшерү уздыру» административ процедурасы

5.1.1. Лицензиатның планлы документар тикшерүне үткәрү датасын билгеләү өчен тиешле лицензиатны тикшерү планына кертү нигез булып тора. Лицензиатка карата планлы тикшерүне Тикшерүләр планына кертү әлеге Регламентның 2.4.1 пунктында күрсәтелгән нигезләрдә гамәлгә ашырыла.

«Лицензиатка планлы документар тикшерү үткәрү» административ процедурасы түбәндәге гамәлләр тәртибенә ярашлы рәвештә гамәлгә ашырыла:

тикшерүне үткәрү өчен җаваплы булган вазыйфаи затларны билгеләү;

тикшерү уздыру турында күрсәтмә рәсмиләштерү;

лицензиатка тикшерү үткәрелүе турында хәбәр итү;

тикшерүне үткәрү;

тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү, законнарда каралган чараларны тикшерү нәтиҗәләре буенча кабул итү.

Лицензиатка планлы документар тикшерү ТР ДТИ (ТР ДТИ структур бүлекчәсе булган территориаль органы) урнашкан урын буенча үткәрелә.

5.1.2. Тикшерүләр планы нигезендә бүлекләрнең җитәкчеләре (торак зоналары инспекцияләре җитәкчеләре), лицензиатка (алга таба - җаваплы башкаручы) тикшерү үткәрү өчен, бүлекләрнең (торак зоналары инспекцияләренең) вазыйфаи затларыннан (торак зоналары инспекцияләренең) җаваплы башкаручыны (җаваплы башкаручыларны) билгелиләр.

Лицензия контроле буенча чараларда шулай ук Татарстан Республикасы Президентының «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясен төзү турында» 2018 елның 3 маендагы ПУ-346 номерлы Указы белән расланган Күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясе әгъзалары да катнаша ала.

Үтәү вакыты: лицензиатны тикшерә башлаганчы сигез эш көне эчендә.

Эшнең нәтиҗәсе: лицензиатны тикшерү өчен билгеләнгән (билгеләнгән) җаваплы башкаручылар исемлеге (яисә җаваплы башкаручы).

5.1.3. Җаваплы башкаручы:

- лицензиатка тикшерү уздыру турында ТР ДТИ күрсәтмәсе проектын әзерли;

- күрсәтмә проектын имза салу өчен ТР башлыгына, ТР башлыгы урынбасарына җибәрә.

Лицензиатка тикшерү уздыру турында ТР ДТИ күрсәтмәсе проектының формасы әлеге Регламентның 5 нче кушымтасында китерелде (тикшерү уздыру турында күрсәтмәнең үрнәк формасы Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган).

Тикшерү уздыру турындагы әмернамәдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

дәүләт контроле (күзәтчелеге) органының аталышы, шулай ук дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) төре (төрләре);

тикшерүне үткәрүгә вәкаләт бирелгән вазыйфаи затның яисә вазыйфаи затларның, шулай ук тикшерү үткәрү өчен җәлеп ителә торган экспертларның, экспертлык оешмалары вәкилләренең фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре, вазыйфалары;

үзләренә карата тикшерү үткәрелә торган юридик затның аталышы яисә шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме, юридик затларның (аларның филиалларының, вәкиллекләренең, аерымланган структур бүлекчәләренең) урнашу урыннары яисә шәхси эшкуарларның фактта эшчәнлекләрен гамәлгә ашыру урыннары;

тикшерүне максатлары, бурычлары, предметы һәм аны үткәрү вакыты;

тикшерүне үткәрүнең хокукый нигезләре;

тикшерелергә тиешле лицензия таләпләре һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләр, шул исәптән тикшерү кәгазенең (контроль сораулар исемлегенең) реквизитлары, әгәр планлы тикшерү уздырганда тикшерү кәгазе (контроль сораулар исемлеге) кулланылырга тиешле булса;

тикшерүне үткәрүнең максатларына һәм бурычларына ирешү өчен зарури булган контрольлек чараларын үткәрү вакытлары һәм аларның исемлеге;

дәүләт контролен (күзәтчелеген) үтәү буенча административ регламентлар исемлеге;

тикшерүне үткәрүнең максатларына һәм бурычларына ирешү өчен юридик затлар, шәхси эшкуарлар тарафыннан тапшырылырга тиешле документлар исемлеге;

тикшерүне үткәрә башлау һәм тәмамлау даталары;

бүтән белешмәләр, әгәр дә бу хәл ТР ДТИ башлыгының, ТР ДТИ башлыгы урынбасарының күрсәтмәсенең үрнәк рәвешендә каралган булса.

Планлы документар тикшерү уздыру турында күрсәтмә ТР ДТИ башлыгы, ТР ДТИ башлыгы урынбасары тарафыннан имзалана.

Үтәү вакыты: тикшерүне уздыра башлаганчыга кадәр алты эш көне эчендә.

Эшнең нәтиҗәсе: планлы документар тикшерү уздыру турында ТР ДТИ башлыгы, ТР ДТИ башлыгы урынбасары тарафыннан имзаланган күрсәтмә.

5.1.4. Җаваплы башкаручы лицензиатка тикшерү уздыру турында күрсәтмә күчермәсен кулга тапшыру турында белдереп, почта аша заказлы хат җибәрү юлы белән һәм (яисә) көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган һәм юридик затның, шәхси эшкуарның электрон почта адресына җибәрелгән электрон документ рәвешендә, әгәр мондый адрес тиешенчә юридик затларның бердәм дәүләт реестрында, шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрында булса, яисә юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан ТР ДТИ элегрәк тапшырылган булса, яисә бүтән үтемле ысул белән планлы документар тикшерү уздырылачагы хакында хәбәр итә.

Лицензиат адресына планлы документар тикшерү үткәрү турындагы күрсәтмәнең күчермәсен җибәрү ТР ДТИ эш алып бару кагыйдәләре нигезендә билгеләнгән тәртиптә теркәлә.

Үтәү вакыты: планлы документлар тикшерү башланганчы өч эш көненнән дә соңга калмыйча.

Эшнең нәтиҗәсе: лицензиат адресына җибәрелгән планлы документар тикшерү үткәрү турында күрсәтмә күчермәсе.

Лицензиат, планлы документар тикшерүне үткәрү турындагы күрсәтмәнең күчермәсен алганнан соң, ун эш көне эчендә, тикшерү үткәрү турындагы күрсәтмәнең күчермәләрен ТР ДТИ җибәрергә тиеш.

Әгәр Россия Федерациясе законнарында башкача каралмаса, ТР ДТИ тапшырыла торган документларның күчермәләрен нотариаль яктан таныклауны таләп итү рөхәт ителми.

Документар тикшерү уздырылганда ТР ДТИ юридик заттан, шәхси эшкуардан документар тикшерү предметына карамаган белешмәләрне һәм документларны, шулай ук ТР ДТИ тарафыннан башка дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнарыннан, муниципаль контроль органнарыннан алынырга мөмкин булган белешмәләрне һәм документларны таләп итәргә хокуклы түгел.

5.1.5. Планлы документар тикшерүне үткәрү барышында җаваплы башкаручы, беренче чиратта, ТР ДТИ карамагында булган, тикшерелә торган затның документларын, шул исәптән, билгеләнгән тәртиптә күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген башкаруга лицензия бирү турында, күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген башкаруга лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында тапшырылган гаризаларны һәм мондый гаризаларга теркәлгән документларны, алдагы тикшерүләрнең актларын, административ хокук бозулар турындагы эшләрне карау материалларын һәм әлеге тикшерелә торган затка карата лицензия контроле нәтиҗәләре турында башка документларны карый. Тикшерүне уздыруның максаты - күрсәтелгән гаризаларда һәм аларга кушымта итеп бирелгән белешмәләрнең законда билгеләнгән лицензия таләпләренә һәм шартларына, шулай ук Юридик затларның бердәм дәүләт реестрында булган белешмәләргә, лицензиатларга - юридик затларга карата һәм Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрында булган белешмәләргә лицензиатларга - шәхси эшкуарларга, башка федераль мәгълүмат ресурсларына карата туры килүен бәяләү.

ТР ДТИ карамагындагы документлардагы белешмәләрнең дөреслеге нигезле шик тудырса яисә әлеге белешмәләр тикшерелә торган зат тарафыннан лицензия таләпләренең үтәлешен бәяләргә мөмкинлек бирми, әгәр хаталар һәм (яисә) каршылыклар ачыкланса, җаваплы башкаручы:

- бу турыда мәгълүмат белән лицензиатка мотивацияләнгән гарызнамә әзерли һәм ун эш көне дәвамында язма рәвештә кирәкле аңлатмалар бирүне таләп итә;

- гаризаны имза салу өчен ТР ДТИ башлыгына, ТР ДТИ башлыгы урынбасарына җибәрә.

- Имзалаганнан соң ТР ДТИ башлыгы, ТР ДТИ башлыгы урынбасары, ТР ДТИ җитәкчесенең планлы документар тикшерү уздыру турындагы күрсәтмәсенең күчермәсе белән беркетелгән дәлилләнгән гаризаны, тапшыру турында белдереп, яисә мөмкин булган башка ысул белән (факс, электрон элемтә, кулга тапшырып) лицензиат адресына заказлы почта юлламасы итеп җибәрә.

Документар тикшерү уздырылганда ТР ДТИ юридик заттан, шәхси эшкуардан документар тикшерү предметына карамаган белешмәләрне һәм документларны, шулай ук ТР ДТИ  тарафыннан башка дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнарыннан, муниципаль контроль органнарыннан алынырга мөмкин булган белешмәләрне һәм документларны таләп итәргә хокуклы түгел, шул исәптән ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша электрон формада гаризалар ярдәмендә дә.

Үтәү вакыты: лицензиатка тикшерү башланган көннән алып биш эш көне эчендә.

Эшнең нәтиҗәсе: хат (нигезле гариза), кирәкле аңлатмалар бирүне таләп итеп, лицензиатка язма рәвештә җибәрелгән хат.

5.1.6. ТР ДТИ тапшырылган документларда ачыкланган хаталарга һәм (яки) каршылыкларга карата яисә бу документларда булган белешмәләрнең ТР ДТИ булган документлардагы белешмәләргә туры килмәвенә карата аңлатмалар тапшыручы лицензиат ТР ДТИ элегрәк тапшырылган документларның дөреслеген раслый торган документларны өстәмә рәвештә тапшырырга хокуклы.

Мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән документлар мөһер (булган очракта) һәм шәхси эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең, юридик зат җитәкчесенең, башка вазыйфаи затының тиешенчә имзасы белән таныкланган күчермәләре рәвешендә тапшырыла. Юридик зат, шәхси эшкуар мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән документларны көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документлар рәвешендә дә тапшырырга хокуклы.

Урынга чыгып тикшерү үткәргәндә юридик заттан, шәхси эшкуардан документар тикшерү үткәрү барышында алар тарафыннан тапшырылган документларны һәм (яки) мәгълүматларны таләп итү тыела.

Җаваплы башкаручы тикшерүләрне оештырганда һәм уздырганда түләүсез нигездә, шул исәптән электрон рәвештә, РФ Хөкүмәтенең 724-р номерлы боерыгы белән расланган исемлеккә кертелгән, әлеге Регламентның 5 нче кушымтасында китерелгән документларны һәм (яисә) мәгълүматларны шушы документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән эш итүче бүтән дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалардан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында РФ Хөкүмәтенең 323 номерлы карары белән билгеләнгән чорларда һәм тәртиптә сората һәм ала.

Җаваплы башкаручы тапшырылган документларны һәм (яки) аңлатмаларны карый. Әгәр дә тапшырылган аңлатмаларны һәм (яки) документларны караганнан соң яисә аңлатмалар булмаганда шушы Регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән лицензия таләпләренең бозылу билгеләре ачыкланса, җаваплы башкаручы, урынга чыгып тикшерү үткәрү турында әмернамә проектын әзерләү юлы белән, урынга чыгып тикшерү үткәрүнең инициаторы була. Урынга чыгып тикшерү үткәрү турында карарны ТР ДТИ башлыгы, ТР ДТИ башлыгы урынбасары кабул итә.

Урынга чыгып тикшерү (аны үткәрү турында карар кабул ителгәндә) шушы Регламентның 5.2 бүлекчәсендә китерелгән тәртипкә туры китереп гамәлгә ашырыла.

Үтәү вакыты: аңлатмаларны алганнан соң өч эш көне дәвамында.

Эшнең нәтиҗәсе: лицензиат тарафыннан тапшырылган, каралган

аңлатмалар һәм (яки) документлар; кирәк булганда, урынга чыгып тикшерү үткәрү турында әмернамә проекты.

5.1.7. Җаваплы башкаручы лицензиат документларында булган белешмәләрне бәяләү нигезендә ике нөсхәдә әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында китерелгән форма буенча тикшерү актын төзи, шулай ук уздырылган тикшерү турында тиешле язуны тикшерүләрне исәпкә алу журналына кертә (андый журнал булган очракта). Тикшерүләрне исәпкә алу журналы булмаганда, тикшерү актында тиешле язу теркәлә.

Контрольлек чарасы нәтиҗәсендә лицензия таләпләренең бозылуы, шул исәптән лицензия таләпләренең җитди бозылуы ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы түбәндәге эшләрне гамәлгә ашыра:

- законнардагы таләпләр бозылуның (лицензия таләпләре, шул исәптән лицензия таләпләренең җитди бозылуның) ачыкланган барлык очракларын тикшерү актында терки;

- тикшерү актына кушымта булып торучы, үтәү өчен мәҗбүри булган лицензия таләпләре, шул исәптән лицензия таләпләренең җитди бозылуын бетерү турында күрсәтмәләр (әлеге Регламентның 2 нче кушымтасына туры китерелгән формада) бирә һәм күрсәтелгән күрсәтмәләрнең билгеләнгән срокларда үтәлүен тикшерүдә тота.

Күрсәтмәләр тикшерү актының аерылгысыз кушымтасы булып тора һәм тикшерелә торган затка (яки аның вәкаләтле затларына) тикшерү акты нөсхәсе белән берьюлы тапшырылырга тиеш.

Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 7.22, 7.23 статьяларында, 7.23.2 статьясының 1 өлешендә, 7.23.3 статьясында, 9.16 статьясының 4 һәм 5 өлешләрендә, 13.19.2 статьясының 1 өлешендә, 14.1.3 статьясында, 19.5 статьясының 4 өлешендә каралган административ хокук бозу билгеләре ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы әлеге Регламентның 3 нче кушымтасына ярашлы форма буенча административ хокук бозу турында беркетмә төзү юлы белән административ хокук бозу турында эш кузгата һәм билгеләнгән тәртиптә аның карап тикшерелүен тәэмин итә.

Административ хокук бозу турында эшләр кузгату һәм административ хокук бозу турында эшләрне алып бару Административ хокук бозулар турында РФ кодексы нигезендә гамәлгә ашырыла.

Тикшерү тәмамлангач барлык материаллар да аерым эш итеп формалаштырыла һәм вакыты чикләнмәгән рәвештә ТР ДТИ сакланырга тиеш.

Контрольлек чарасы барышында контрольлек буенча чара уздыру объекты булып торган кълпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча

эшкуарлык эшчәнлегенең законнардагы таләпләрне бозуга бәйле икәнлеге ачыкланган очракта, аларны ачыклау, туктату һәм чикләү мәсьәләләре ТР ДТИ компетенциясенә карамаса, ТР ДТИ Россия Федерациясенең яисә Татарстан Республикасының тиешле вәкаләтле дәүләт хакимияте органнарына мондый бозулар турында мәгълүматларны (белешмәләрне) җибәрергә бурычлы.

Җаваплы башкаручы тикшерү актының бер нөсхәсен (кушымталары белән бергә) лицензия эшенә формалаштыра һәм ачыкланган очракта бозулар бетерелгәнчегә кадәр тикшерүдә тота, икенчесен (кушымталары белән бергә) юридик затның җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә кулга алу һәм танышып чыгу турында язу яздыртып яки тикшерү акты белән танышудан баш тарту турында тамгалап тапшыра.

Юридик затның җитәкчесе, бүтән вазыйфаи заты яисә вәкаләтле вәкиле, шәхси эшкуар, аның вәкаләтле вәкиле булмаган очракта, шулай ук тикшерелә торган затның тикшерү акты белән танышып чыгуы турында яисә танышып чыгудан баш тарту турындагы имза куясы килмәсә, акт кулга тапшыру тамгасы белән почта аша заказлы хат итеп җибәрелә, кулга алу турындагы белдерүнамә ТР ДТИ эшендә саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә теркәлә. Тикшерелә торган затның электрон рәвештә хезмәттәшлек итүгә ризалыгы булган очракта, тикшерү акты юридик затның җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә шушы актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелергә мөмкин. Шул ук вакытта бу актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган, тикшерелә торган затка әлеге документның алынуын раслауны тәэмин итә торган ысул белән электрон документ рәвешендә җибәрелгән акт тикшерелә торган зат тарафыннан алынган дип исәпләнә.

Үтәү вакыты:

- тикшерү актын кушымталары белән тапшыру: тикшерү тәмамланганнан соң турыдан-туры;

- тикшерү актын кушымталары белән заказлы хат итеп җибәрү: тикшерү чаралары тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә:

- беркетмә төзү – административ хокук бозуның кылынганлыгы ачыклану белән кичекмәстән.

Эш нәтиҗәсе:

- ике нөсхәдә төзелгән тикшерү акты, аның берсе лицензиатка тапшырылган (җибәрелгән), икенчесе, ачыкланган очракта, бозулар

бетерелгәнчегә кадәр тикшерүдә тотып, лицензия эшенә теркәп куелган;

лицензия таләпләренең бозылуы, шул исәптән лиция таләпләренең җитди бозылуы, ачыкланганда:

- күрсәтмә;

- административ хокук бозу турында беркетмә.

Юридик затка, шәхси эшкуарга үзләренә бәйле булмаган сәбәпләр аркасында билгеләнгән срокта бозуларны бетерү турында күрсәтмә таләпләрен үтәү мөмкин булмаган очракта, күрсәтмә бирелгән юридик зат, шәхси эшкуар күрсәтмәне үтәү срогы тәмамланырга кимендә биш эш көненнән соңга калмыйча ТР ДТИгә бозуны бетерү һәм күрсәтмәне үтәү срогын озынайту турында гозер белән үтенеч язуын җибәрәләр. Үтенеч язуына юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан билгеләнгән срокта бозуларны бетерү өчен чараларның тулысынча күрелүен раслаучы документлар теркәлә.

Үтенеч язуын канәгатьләндерү турында (канәгатьләндерүдән баш тарту турында) карарны ТР ДТИ җитәкчесе (җитәкче урынбасары ) үтенеч язуы ТР ДТИдә теркәлгән көннән соң өч эш көненнән артмаган срокта кабул итә. Үтенеч язуын канәгатьләндерүдән баш тарту турында карар нигезле булырга тиеш. Әгәр күрсәтмәдә билгеләнгән срокта бозу очрагын бетерү мөмкин булмаса, ләкин күрсәтмә бирелгән юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан ачыкланган бозуны бетерү өчен кирәкле, аларга бәйле булган барлык чаралар күрелмәсә, күрсәтмәне үтәү срогын озынайтудан баш тарту турында карар кабул ителә.

Үтенеч язуын канәгатьләндерү турында карар кабул ителгән очракта ТР ДТИнең күрсәтмәне биргән вазыйфаи заты күрсәтмәне үтәү вакытын озынайту турында белдерү (әлеге Регламентка 7 нче кушымта) төзи һәм аны имза кую өчен ТР ДТИ башлыгына (җитәкче урынбасары на) юллый.

Үтәү вакыты: күрсәтмәне үтәү вакытын арттыру турында гозерне үз эченә алган язмача үтенеч язуы теркәлгән көннән башлап өч эш көне эчендә.

Эшнең нәтиҗәсе: юридик затка, шәхси эшкуарга җибәрелгән күрсәтмәне үтәү срогын озынайту турында белдерү яки күрсәтмәне үтәү срогын озынайтудан баш тарту турында язмача җавап.

Күрсәтмәне үтәү срогын озынайту турында белдерү алганда юридик зат, шәхси эшкуар күрсәтмәнең төп нөсхәсен өч эш көне эчендә аңа тиешле язу кертү өчен ТР ДТИгә тапшыра.

Күрсәтмәне үтәү срогын озынайту турында язу ТР ДТИнең күрсәтмәне биргән вазыйфаи заты тарафыннан күрсәтмәнең ике (юридик зат, шәхси эшкуар тапшырган нөсхәгә һәм ТР ДТИ эшендә саклана торган нөсхәгә)

нөсхәсенә дә кертелә һәм ТР ДТИнең күрсәтмәне биргән вазыйфаи затының имзасы белән таныклана. Язу кертелгәннән соң күрсәтмә нөсхәсен кулга алганда юридик затның, шәхси эшкуарның вәкиле аның белән танышып чыгу турында кул куя.

Әгәр билгеләнгән срокта тикшерелә торган зат лицензия таләпләре бозылуны, шул исәптән лицензия таләпләренең җитди бозылуын, бетермәсә, ТР ДТИ судка мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

5.1.7.1. Планнан тыш тикшерү уздырылганда билгеләнгән чорда лицензия таләпләренең ачыкланган бозуларын юкка чыгару турында законлы күрсәтмәнең үтәлмәгәнлеге ачыкланса, җаваплы башкаручы:

1) Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 19.5 статьясының 24 өлешендә каралган административ хокук бозу буенча эш кузгата;

2) билгеләнгән чорда бетерелмәгән бозуларны юкка чыгару турында күрсәтелгән бозуларны бетерү вакытын күрсәтеп күрсәтмә бирә.

5.1.8. «Лицензиатка карата планлы документар тикшерү үткәрү» административ процедурасын үтәү нәтиҗәсе электрон формада ТР ДТИ рәсми сайтында теркәлә. Тиешле мәгълүмат билгеләнгән тәртиптә тикшерүләрнең бердәм реестрына, «Контрольлек (күзәтчелек) эшчәнлеген автоматлаштыру буенча бертип болыт чишелеше» дәүләт мәгълүмат системасына кертелә.

## 5.2. «Лицензиатка планлы документар тикшерү уздыру» административ процедурасы

5.2.1. Лицензиатка планлы тикшерү үткәрү датасын билгеләү өчен тиешле лицензиатны тикшерү планына кертү нигез булып тора, шулай ук, әгәр документар тикшерү барышында түбәндәгеләр мөмкин булмаса:

1) ТР ДТИ карамагындагы лицензиат документларындагы белешмәләрнең тулылыгын һәм дөреслеген тикшерергә;

2) лицензиат эшчәнлегенең лицензия таләпләренә туры килү-килмәвен контрольлек буенча тиешле чара үткәрмичә бәяләү.

Административ процедура әлеге Регламентның 5.1.1 пунктында күрсәтелгән шундый ук административ гамәлләр тәртибенә ярашлы рәвештә гамәлгә ашырыла.

Планлы күчмә тикшерү юридик зат урнашкан урын, шәхси эшкуарның эшчәнлеге гамәлгә ашырылган урын буенча һәм (яисә) аларның эшчәнлекләре фактта гамәлгә ашырылган урын буенча уздырыла.

5.2.2. Лицензиатны тикшерү өчен җаваплы башкаручыны (җаваплы башкаручыларны) билгеләү, тикшерү үткәрү турында күрсәтмә әзерләү, планлы күчмә тикшерү үткәрү турында лицензиатка хәбәр итү әлеге Регламентның 5.1.2 - 5.1.4 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Күчмә тикшерү уздырганда экспертлар, эксперт оешмалары вәкилләре, ТР ДТИ башлыгы, ТР ДТИ башлыгы урынбасары экспертларны, эксперт оешмалары вәкилләрен федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә җәлеп итә.

5.2.3. Планлаштырылган күчмә тикшерү түбәндәгечә үткәрелә.

Җаваплы башкаручы (җаваплы башкаручылар) лицензиат объектына килгәннән соң тикшерү башлый (башлыйлар):

- хезмәт таныклыгын күрсәтеп;

- лицензиат җитәкчесенең яисә аның башка вазыйфаи затының, аның вәкаләтле вәкиленең ТР ДТИ башлыгы, ТР ДТИ башлыгы урынбасары күчмә тикшерүне билгеләү турында күрсәтмәсе белән мәҗбүри танышуы белән;

- юридик зат җитәкчесенә яисә вазыйфаи затына, аның вәкаләтле вәкиленә урынга чыгып тикшерү уздыручы затларның вәкаләтләре, шулай ук урынга чыгып уздырылган тикшерүнең максатлары, бурычлары, нигезләре, контрольлек чараларының төрләре һәм күләмнәре, урынга чыгып тикшерү уздыру өчен җәлеп ителүче экспертларның составы, эксперт оешмалары вәкилләре, аны уздыру вакытлары һәм шартлары белән мәҗбүри таныштырып.

Җаваплы башкаручы лицензиат эшчәнлегенең әлеге Регламентның 3 бүлегендә китерелгән лицензия таләпләренә туры килүен бәяли.

Экспертлар, эксперт оешмалары вәкилләре ТР ДТИ тарафыннан куелган мәсьәләләр буенча чаралар үткәрә.

Үткәрү вакыты: Регламентның 2.3.1 пунктында күрсәтелгән срокларда.

Эш нәтиҗәсе: контрольлек буенча үткәрелгән чаралар.

5.2.4. Җаваплы башкаручы лицензион контроль буенча үткәрелгән чаралар нигезендә әлеге Регламентка 1 нче кушымтада китерелгән форма буенча ике нөсхәдә тикшерү төзи. Тикшерү актын төзү шушы Регламентның 5.1.7 пунктында күрсәтелгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Лицензия таләпләрен бозу очраклары ачыкланган очракта, тикшерү актына түбәндәгеләр теркәлә:

- ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү срогы күрсәтелеп, лицензия таләпләрен бозуларны бетерү турында күрсәтмә;

- үткәрелгән тикшерүләр, сынаулар һәм экспертизалар беркетмәсе яки бәяләмәсе (булган очракта);

- күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген башкаруга лицензиясе булган лицензиат хезмәткәрләренең аңлатмалары;

- тикшерү нәтиҗәләренә бәйле башка документлар яки аларның күчермәләре.

Әгәр тикшерү актын төзү өчен үткәрелгән тикшеренүләрнең, сынауларның, махсус тикшерүләрнең, экспертизаларның бәяләмәсен алу кирәк булса, тикшерү акты контрольлек чараларын тәмамлаганнан соң өч эш көненнән артып китмәгән чорда төзелә һәм лицензиатка кул куйдыртып тапшырыла яисә кулга тапшыру тамгасы белән почта аша заказлы хат итеп җибәрелә һәм (яисә) шушы актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә (тикшерелүче затның электрон рәвештә хезмәттәшлек итүне гамәлгә ашыруга ризалыгы булган очракта), күрсәтелгән документның алынуын тәэмин итүче ысул белән җиткерелә. Бу вакытта кулга тапшыру турыда белдерү һәм (яисә) күрсәтелгән документның алынуына бүтәнчә дәлилләмә тикшерү актының ТР ДТИ саклана торган эштәге нөсхәсенә кушып куела.

5.2.5. Уздырылган тикшерү турында тикшерүләрне исәпкә алу журналында (булган очракта) язу терки, анда уздырылган тикшерү турындагы язуда дәүләт контроле (күзәтчелеге) органының аталышы, тикшерүне уздыра башлау һәм тәмамлау даталары, аны уздыру вакыты, тикшерүнең хокукый нигезләре, максатлары, бурычлары һәм предметы турында белешмәләр була, шулай ук тикшерүне уздыручы вазыйфаи затның яки вазыйфаи затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре һәм вазыйфалары, аның яки аларның имзалары күрсәтелә. Тикшерүләрне исәпкә алу журналы булмаганда, тикшерү актында тиешле язу теркәлә.

Үтәү вакыты: тикшерү тәмамланганнан соң турыдан-туры.

Эш нәтиҗәсе: лицензиатның тикшерүләрне исәпкә алу журналында үткәрелгән планлы тикшерү турында язу.

5.2.5.1. Әгәр шәхси эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең, юридик зат җитәкчесенең яки башка вазыйфаи затының булмавына бәйле рәвештә, яисә юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан эшчәнлекнең фактта башкарылмавына бәйле рәвештә, шәхси эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең, юридик зат җитәкчесенең яки башка вазыйфаи затының бүтән төрле, тикшерүне үткәрү мөмкинлеген юкка чыгаручы гамәлләре (гамәл кылмавы) аркасында планлы яки планнан тыш урынга чыгып тикшерүне

үткәрү мөмкин булмаса, ТР ДТИ вазыйфаи заты, аны үткәрү мөмкинлеген юкка чыгаручы сәбәпләрне күрсәтеп, тиешле тикшерүне үткәрү мөмкинлегенең булмавы хакында акт төзи. Бу очракта ТР ДТИ, тиешле тикшерүне үткәрү мөмкинлегенең булмавы хакында акт төзелгән көннән башлап өч ай дәвамында, мондый юридик затка, шәхси эшкуарга карата, планлы тикшерүне еллык планлы тикшерүләр планына кертмичә һәм юридик затка, шәхси эшкуарга алдан хәбәр итмичә, планлы яки планнан тыш урынга чыгып тикшерү үткәрү турында карар кабул итәргә хокуклы.

5.2.6. «Лицензиатка карата урынга чыгып планлы тикшерү үткәрү» административ процедурасын үтәү нәтиҗәсе электрон формада ТР ДТИ рәсми сайтында теркәлә. Тиешле мәгълүмат билгеләнгән тәртиптә тикшерүләрнең бердәм реестрына, «Контрольлек (күзәтчелек) эшчәнлеген автоматлаштыру буенча бертип болыт чишелеше» дәүләт мәгълүмат системасына кертелә.

### 5.3. «Лицензиатка, лицензия алырга теләүчегә планнан тыш документар тикшерү уздыру» административ процедурасы»

5.3.1. Әлеге Регламентның 2.4.2, 2.4.4 пунктларында күрсәтелгән очраклар «Лицензиатка, лицензия алырга теләүчегә планнан тыш документар тикшерү үткәрү» административ процедурасын башлау өчен нигез булып тора.

«Лицензиатка, лицензия алырга теләүчегә планнан тыш документар тикшерү үткәрү» административ процедурасы әлеге Регламентның 5.1.1 пунктында күрсәтелгән шундый ук административ гамәлләр тәртибенә ярашлы рәвештә гамәлгә ашырыла.

Лицензиатка, лицензия алырга теләүчегә планнан тыш документар тикшерү ТР ДТИ урнашкан урында үткәрелә.

5.3.2. Әлеге Регламентның 2.4.2, 2.4.4 пунктларында күрсәтелгән планнан тыш документар тикшерүне үткәрү өчен нигезләр барлыкка килгәндә, ТР ДТИ җитәкчесе урынбасары, әлеге Регламентның 2.4, 2.4.4 пунктларында күрсәтелгән планнан тыш документар тикшерүне оештыру һәм үткәрү турында бүлекләр җитәкчеләренә, торак зонасы инспекцияләре җитәкчеләренә күрсәтмә бирә.

Бүлекләрнең җитәкчеләре, торак зоналары инспекцияләре җитәкчеләре бүлекләрнең (дәүләт торак инспекторларының) вазыйфаи затларыннан, торак зонасы инспекцияләреннән лицензия алырга теләүче затка, лицензиатка тикшерү үткәрү өчен җаваплы башкаручыны билгелиләр.

Үтәү вакыты: тикшерү үткәрү өчен нигезләр барлыкка килгән көннән соң бер эш көне эчендә.

Эш нәтиҗәсе: ТР ДТИ башлыгының, ТР ДТИ башлыгы урынбасарының планнан тыш документар тикшерүне оештыру һәм уздыру турында йөкләмәсе, лицензиатны, лицензия алырга теләүчене тикшерү өчен билгеләнгән җаваплы башкаручы.

5.3.3. ТР ДТИ башлыгының, ТР ДТИ башлыгы урынбасарының планнан тыш документар тикшерүне оештыру һәм уздыру турында күрсәтмәсен әзерләү әлеге Регламентның 5.1.3 пункты нигезендә лицензиатны, лицензия алырга теләүчене тикшерү өчен билгеләнгән җаваплы башкаручы билгеләнгән көнне гамәлгә ашырыла.

5.3.4. Планнан тыш документар тикшерү үткәргәндә шушы Регламентның 5.1.5, 5.1.6 пунктлары нигезендә гамәлләр башкара (лицензиатның, лицензия алырга теләүченең гаризаларында һәм документларында булган белешмәләрне бәяли, алар адресларына хатлар (дәлилләнгән гаризалар) әзерли, лицензиатның, лицензия алырга теләүченең аңлатмаларын карап тикшерә).

5.3.5. Лицензиатка, лицензия алырга теләүчегә карата документар тикшерүнең предметы булып, әлеге белешмәләрнең «Аерым эшчәнлек төрләрен лицензияләү турында» 2011 елның 04 маендагы 99-ФЗ номерлы федераль закон нигезләмәләренә, шулай ук Юридик затларның бердәм дәүләт реестрында, Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрында һәм башка федераль мәгълүмат ресурсларында лицензиат, лицензия алырга теләүче турында булган белешмәләргә туры килүен бәяләү максатларында, тапшырылган гаризаларда һәм документларда булган белешмәләр тора.

5.3.6. Тикшерү актын төзү һәм лицензиатны, лицензия алырга теләүче затны тикшерү акты (кушымталар, шул исәптән, рәсмиләштерү зарурлыгы булганда, күрсәтмә белән) белән таныштыру, тикшерүләрне исәпкә алу журналына язу теркәү яисә тикшерү актына тиешле язу кертү (тикшерүләрне исәпкә алу журналы булмаган очракта), беркетмә белән таныштыру (аны рәсмиләштерү зарурлыгы булган очракта) әлеге Регламентның 5.1.7 пункты нигезендә гамәлгә ашырыла.

Тикшерү акытнда ачыкланган яңа җитешсезлекләр, шулай ук системалы характерда булган хокук бозу очраклары зарури тәртиптә теркәлә.

5.3.7. «Лицензиатка, лицензия алырга теләүче затка карата планнан тыш документар тикшерү үткәрү» административ процедурасын үтәү нәтиҗәсе электрон формада ТР ДТИ рәсми сайтында теркәлә. Тиешле мәгълүмат билгеләнгән тәртиптә тикшерүләрнең бердәм реестрына, «Контрольлек (күзәтчелек) эшчәнлеген автоматлаштыру буенча бертип болыт чишелеше» дәүләт мәгълүмат системасына кертелә.

**5.4. «Лицензиатка, лицензия алырга теләүчегә планнан тыш урынга**

**чыгып тикшерү уздыру» административ процедурасы»**

5.4.1. Административ процедураны башлап җибәрү өчен әлеге Регламентның 2.4.2, 2.4.4 пунктларында күрсәтелгән очраклар, шулай ук документар тикшерү вакытында түбәндәгеләр мөмкин булмаса да, нигез булып тора:

1) ТР ДТИ карамагындагы лицензиат, лицензия алырга теләүче документларындагы белешмәләрнең тулылыгын һәм дөреслеген тикшерергә;

2) лицензия алырга теләүченең, лицензиат эшчәнлегенең лицензия таләпләренә туры килү-килмәвен контрольлек буенча тиешле чара үткәрмичә бәяләргә.

Планнан тыш күчмә тикшерүләр, шушы Регламентның 2.4.2 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән нигез буенча планнан тыш күчмә тикшерү уздырудан тыш, прокуратура органы белән килештерелмичә уздырыла.

«Лицензиатка, лицензия алырга теләүчегә планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү» административ процедурасы әлеге Регламентның 5.1.1 пунктында күрсәтелгән шундый ук административ гамәлләр тәртибенә ярашлы рәвештә гамәлгә ашырыла.

Планнан тыш күчмә тикшерү юридик зат урнашкан урын, шәхси эшкуарның эшчәнлеге гамәлгә ашырылган урын буенча һәм (яисә) аларның эшчәнлекләре фактта гамәлгә ашырылган урын буенча уздырыла.

5.4.2. Лицензиатка, лицензия алырга теләүчегә планнан тыш тикшерү үткәрү өчен җаваплы башкаручыны билгеләү әлеге Регламентның 5.3.2 пунктының икенче абзацы нигезендә гамәлгә ашырыла.

Күчмә тикшерү уздырганда экспертлар, эксперт оешмалары вәкилләре, ТР ДТИ башлыгы, ТР ДТИ башлыгы урынбасары экспертларны, эксперт оешмалары вәкилләрен федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә җәлеп итә.

5.4.3. Җаваплы башкаручы тарафыннан лицензиатка, лицензия алырга теләүчегә планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында күрсәтмә әзерләү шушы Регламентның 5.1.3 пункты нигезендә гамәлгә ашырыла.

5.4.4. Планнан тыш тикшерү үткәрү өчен лицензиат тарафыннан лицензия таләпләрен җитди бозу очраклары турында ТР ДТИ гражданнардан алынган мөрәҗәгатьләр, гаризалар, шул исәптән шәхси эшкуарлардан, юридик затлардан, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан алынган мәгълүмат нигез булып торса, җаваплы башкаручы:

- лицензиатның эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча прокуратура органына лицензиаткаң планнан тыш урынга чыгып тикшерү үткәрүне

килештерү турында гариза әзерли һәм аңа ТР ДТИ башлыгы, ТР ДТИ башлыгы урынбасары тарафыннан имза куйдырттыра (планнан тыш тикшерү уздыруны прокуратура органы белән килештерү турында гаризаның бер төр үрнәге әлеге Регламентның 6 нчы кушымтасында китерелгән);

- планнан тыш күчмә тикшерү уздыруны килештерү турындагы гаризаны юридик затның, шәхси эшкуарның лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру урыны буенча прокуратура органына турыдан-туры тапшыра яки, кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы итеп җибәрә яки көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында юллый. Бу гаризага ТР ДТИ башлыгы, ТР ДТИ башлыгы урынбасарының планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турындагы күрсәтмәсенең күчермәсе һәм аны үткәрүгә нигез булган документлар теркәлә.

Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы белән лицензиатны планнан тыш күчмә тикшерүне үткәрү прокуратурасы органы белән килештерү тәртибе, шулай ук прокуратура органын планнан тыш күчмә тикшерүне уздыруны килештерү өчен раслау тәртибе Россия Генераль прокуратурасының 93 номерлы боерыгында билгеләнгән.

Үтәү вакыты: лицензиатка планнан тыш тикшерү үткәрү турындагы күрсәтмәгә кул куелган көнне.

Эш нәтиҗәсе: прокуратура органына җибәрелгән планнан тыш тикшерү үткәрүне килештерү турында гариза.

5.4.5. Җаваплы башкаручы лицензиатка урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәреләчәге турында (әлеге Регламентның 2.4.2 пунктындагы 1, 3 пунктчаларда күрсәтелгән нигезләрдә үткәрелә торган урынга чыгып планнан тыш тикшерүдән гайре) аны уздыра башларга кимендә егерме дүрт сәгать алдан теләсә нинди үтемле ысул белән, шул исәптән көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган һәм юридик затның, шәхси эшкуарның электрон почта адресына җибәрелгән электрон документ рәвешендә хәбәр итә, әгәр мондый адрес юридик затларның бердәм дәүләт реестрында, шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрында тиешенчә булса, яисә юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан ТР ДТИ элегрәк тапшырылган булса.

ТР ДТИ планнан тыш урынга чыгып тикшерүне әлеге Регламентның 2.4.2 пунктының 1, 3 пунктчаларында күрсәтелгән нигез буенча алдан хәбәр юлламыйча да уздырырга хокуклы.

5.4.6. Планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү шушы Регламентның 5.2.3 пунктында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

5.4.7. Тикшерү актын төзү әлеге Регламентның 5.2.4 пункты нигезендә

башкарыла.

Әгәр планнан тыш тикшерү прокуратура органы белән килештереп башкарылса, тикшерү актының күчермәсе тикшерү акты төзелгән көннән алып биш эш көне эчендә прокуратура органына җибәрелә.

5.4.8. Әгәр шәхси эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең, юридик зат җитәкчесенең яки башка вазыйфаи затының булмавына бәйле рәвештә, яисә юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан эшчәнлекнең фактта башкарылмавына бәйле рәвештә, шәхси эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең, юридик зат җитәкчесенең яки башка вазыйфаи затының бүтән төрле, тикшерүне үткәрү мөмкинлеген юкка чыгаручы гамәлләре (гамәл кылмавы) аркасында планнан тыш урынга чыгып тикшерүне үткәрү мөмкин булмаса, җаваплы башкаручы әлеге Регламентның 5.2.5.1 пунктына туры китереп, гамәлләр башкара.

5.4.8.1. «Лицензиатка, лицензия алырга теләүче затка карата урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрү» административ процедурасын үтәү нәтиҗәсе электрон формада ТР ДТИ рәсми сайтында теркәлә. Тиешле мәгълүмат билгеләнгән тәртиптә тикшерүләрнең бердәм реестрына, «Контрольлек (күзәтчелек) эшчәнлеген автоматлаштыру буенча бертип болыт чишелеше» дәүләт мәгълүмат системасына кертелә.

## 5.6. «Лицензиатлар белән элемтәгә кермичә контрольлек чаралары оештыру һәм уздыру» администартив процедурасы

5.6.1. Административ процедураны башлау нигезе булып ТР ДТИ башлыгы, ТР ДТИ башлыгы урынбасары тарафыннан тарафыннан расланган юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән элемтәгә кермичә контрольлек чараларын уздыру биреме тора.

Аларны уздырганда ТР ДТИ белән лицензиатлар булып торучы юридик затлар, шәхси эшкуарлар арасында хезмәттәшлек итү таләп ителми торган контрольлек чараларына (алга таба – лицензиатлар белән элемтәгә кермичә контрольлек чаралары) түбәндәгеләр керә:

1) «Интернет» челтәрендә һәм массакүләм мәгълүмат чараларында мәгълүмат урнаштырылганда лицензия таләпләренең үтәлүен күзәтү;

2) лицензиатның эшчәнлеге яки гамәлләре турында федераль закон нигезендә әлеге затларга аны тапшыру җаваплылыгы йөкләнгән мәгълүматларны анализлау юлы белән лицензия таләпләренең үтәлүен күзәтү (шул исәптән федераль дәүләт мәгълүмат системаларыннан файдалану юлы белән);

3) федераль законнарда билгеләнгән контрольлек чараларының башка

төрләре һәм рәвешләре.

5.6.2. Лицензиатлар белән элемтәгә кермичә контрольлек чаралары ТР ДТИ вазыйфаи затлары тарафыннан үз компетенциясе кысаларында мондый чараларны уздыруга ТР ДТИ башлыгы, ТР ДТИ башлыгы урынбасары тарафыннан расланган биремнәр нигезендә уздырыла.

5.6.3. Биремнәрне рәсмиләштерү тәртибен һәм аларның эчтәлекләрен һәм лицензиат белән элемтәгә кермичә контрольлек чараларының нәтиҗәләрен ТР ДТИ вазыйфаи затлары тарафыннан рәсмиләштерү тәртибен ТР ДТИ билгели.

5.6.4. Әлеге Регламентның 5.6.1 пунктында күрсәтелгән контрольлек чараларын уздырганда лицензия таләпләренең бозылу очраклары ачыкланганда, ТР ДТИ вазыйфаи затлары үз компетенциясе кысаларында мондый бозуларны чикләү буенча чаралар күрә, шулай ук язмача формада ТР ДТИ башлыгына, ТР ДТИ башлыгы урынбасарына зарурлык булганда әлеге Регламентның 2.4.2 пунктының 7 пунктчасында күрсәтелгән нигезләрдә лицензиатка планнан тыш тикшерү билгеләү турында карар кабул итү өчен ачыкланган бозулар турында мәгълүмат белән дәлилле йогынты актын юллыйлар.

Лицензиатлар белән элемтәгә кермичә контрольлек чараларын уздыру барышында әлеге Регламентның 3.3 пунктында күрсәтелгән лицензия таләпләрен бозарга җыюнулар яисә бозу билгеләре турында белешмәләр алынган очракта, ТР ДТИ вазыйфаи затлары лицензиатка РФ Хөкүмәтенең 166 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләрдә каралган тәртиптә һәм срокларда лицензия таләпләрен бозуның ярамаганлыгы турында кисәтү җибәрәләр.

## 6. ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕ ҮТӘЛЕШЕН КОНТРОЛЬДӘ ТОТУ ТӘРТИБЕ ҺӘМ ФОРМАЛАРЫ

### 6.1. ТР ДТИ вазыйфаи затларының әлеге Регламетның һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә карата таләпләр билгели торган башка норматив хокукый актлар нигезләмәләрен үтәвенә һәм башкаруына, шулай ук әлеге затлар тарафыннан карарлар кабул итүгә агымдагы контрольлекне гамәлгә ашыру тәртибе

6.1.1. ТР ДТИ вазыйфаи затлар тарафыннан аларның хезмәт вазыйфалары үтәлүен тикшереп тора, вазыйфаи затлар тарафыннан хезмәт вазыйфалары тиешенчә үтәлмәү очракларының исәбен алып бара, тиешле хезмәт тикшерүләрен үткәрә һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә мондый вазыйфаи затларга карата чаралар күрә.

6.1.2. Әлеге Регламентның үтәлешен контрольдә тоту ТР ДТИ башлыгы

тарафыннан башкарыла. Ул булмаганда, шулай ук аның күрсәтмәсе буенча контроль ТР ДТИ башлыгы урынбасарларының берсенә йөкләнергә мөмкин.

6.1.3. ТР ДТИ вазыйфаи затлары тарафыннан әлеге Регламент нигезләмәләрен һәм дәүләт функцияләрен үтәүгә карата таләпләрне билгеләүче Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив актларын үтәүгә һәм саклауга карата агымдагы контроль ТР ДТИ башлыгы урынбасары һәм ТР ДТИ вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

6.1.4. ТР ДТИ дәүләт функциясе үтәлешенә агымдагы контрольлекне гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеге, әлеге контрольне гамәлгә ашыру тәртибе һәм ешлыгы ТР ДТИ актларында билгеләнә.

Тикшерүләр ТР ДТИ башлыгы, ТР ДТИ башлыгы урынбасары күрсәтмәсе нигезендә үткәрелә. Тикшерү нәтиҗәләре акт рәвешендә рәсмиләштерелә, анда дәүләт функциясен үтәгәндә җитешсезлекләрнең булмавы яки ачыкланган җитешсезлекләр һәм аларны бетерү буенча тәкъдимнәр теркәлә.

6.1.5. Агымдагы контроль ТР ДТИ вазыйфаи заты тарафыннан ТР ДТИ вазыйфаи затлары тарафыннан әлеге Регламент нигезләмәләрен, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларын үтәлешен һәм башкарылуын тикшерү юлы белән гамәлгә ашырыла.

### 6.2. Дәүләт функциясен башкаруның тулы һәм сыйфатлы булуына планлы һәм планнан тыш тикшерүләрне гамәлгә ашыру тәртибе һәм ешлыгы, шул исәптән дәүләт функциясен башкаруның тулы һәм сыйфатлы булуына контроль тәртибе һәм формалары

6.2.1. Планлы һәм планнан тыш тикшерүләр рәвешендә контрольне гамәлгә ашыру тәртибе һәм ешлыгы ТР ДТИ башлыгы, ТР ДТИ башлыгы урынбасары тарафыннан билгеләнә.

Дәүләт функциясенең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын планлы тикшерүләр ТР ДТИ агымдагы елга эш планы нигезендә үткәрелә, ул ТР ДТИ башлыгының дәүләт функциясен башкаруга вәкаләтле урынбасары тарафыннан әлеге планга кертелә. Дәүләт функциясен үтәүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын планнан тыш тикшерүләр дәүләт функциясен үтәү барышында ТР ДТИ вазыйфаи затлар тарафыннан кабул ителгән яисә гамәлгә ашырылган карарларга яки гамәлләргә (гамәл кылмауларына) гражданнарның шикаятьләре нигезендә оештырыла һәм үткәрелә.

6.2.2. Тикшерүләр оештырганда һәм үткәргәндә ТР ДТИ вазыйфаи затларының гамәлләренә карата контроль аларның гамәлләренә карата шикаятьләрне карау кысаларында гамәлгә ашырыла.

6.2.3. Тикшерүне оештыруның һәм үткәрүнең тулы һәм сыйфатлы булуын контрольдә тоту тикшерүләрне оештыруның тулылыгын һәм сыйфатын тикшерү, лицензиатның хокукларын бозу очракларын ачыклау һәм бетерү, лицензиатның ТР ДТИ вазыйфаи затлары карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләрен үз эченә алган мөрәҗәгатен карау, аңа җавап әзерләү һәм карарлар кабул итү кебек эшләрне үз эченә ала.

**6.3. Дәүләт функциясен үтәү барышында алар тарафыннан кабул ителә торган (гамәлгә ашырыла торган) карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмаган) өчен ТР ДТИ вазыйфаи затларының җаваплылыгы**

6.3.1. Тикшерү үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар дәүләт функцияләрен үтәү срокларын һәм билгеләнгән тәртибен үтәү, лицензиатның хокукларын саклау өчен җаваплы була.

6.3.2. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча, тикшерелүче затның хокукларын бозу фактлары ачыкланган очракта, ТР ДТИнең гаепле вазыйфаи затлары Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартылырга тиеш.

6.3.3. Вазыйфаи затларның җаваплылыгы Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә аларның вазыйфаи регламентларында беркетелә.

**6.4. Дәүләт функциясен башкаруга, шул исәптән гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан да, контроль тәртибенә һәм формаларына карата таләпләрне сыйфатлый торган нигезләмәләр**

6.4.1. ТР ДТИ вазыйфаи затлары тарафыннан дәүләт функциясе үтәлешен тикшереп тору ТР ДТИ адресына гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан түбәндәгеләрне җибәрү юлы белән гамәлгә ашырылырга мөмкин:

1) ТР ДТИ вазыйфаи затлары тарафыннан дәүләт функцияләрен үтәүне регламентлаучы норматив хокукый актларны камилләштерү турында тәкъдимнәр;

2) ТР ДТИ, аның вазыйфаи затлары эшендәге җитешсезлекләр, норматив хокукый актлар нигезләмәләрен бозу турында хәбәрләр;

3) ТР ДТИ вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнарның һәм юридик затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозу фактлары буенча шикаятьләр

**7. ТР ДТИ, ШУЛАЙ УК АНЫҢ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРЫНЫҢ КАРАРЛАРЫНА ҺӘМ ГАМӘЛЛӘРЕНӘ (ГАМӘЛ КЫЛМАВЫНА)**

## КАРАТА СУДКА КАДӘР (СУДТАН ТЫШ) ШИКАЯТЬ БЕЛДЕРҮ ТӘРТИБЕ

7.1. Кызыксынган затлар (алга таба – мөрәҗәгать итүчеләр) дәүләт функциясен башкаруда катнашучы вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белән мөрәҗәгать итәргә һәм дәүләт функциясен үтәү барышында башкарыла торган (кабул ителә) карарларга (гамәлләргә) шикаятьләрне шәхсән яисә почта аша яисә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, шул исәптән ТР ДТИ рәсми сайтыннан файдаланып, электрон документ рәвешендә җибәрергә хокуклы.

7.2. Мөрәҗәгать итүче үзенең язма шикаятендә ТР ДТИ атамасын, йә ТР ДТИ вазыйфаи затының вазыйфасын, фамилиясен, исемен, атасын, шулай ук урнашу урыны турында мәгълүматларны – юридик зат өчен; фамилиясен, исемен, атасының исемен (соңгысы – булган очракта) – шәхси эшкуар өчен; җавап җибәрелергә тиешле почта адресын күрсәтә, шикаятьнең асылын бәян итә, шәхси имзасын һәм датаны куя.

7.3. Электрон документ рәвешендә кергән шикаятьтә мөрәҗәгать итүченең (мөрәҗәгать итүче вәкиленең) фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) яисә оешманың тулы исеме, җавап җибәрелергә тиешле электрон почта адресы, мөрәҗәгатьне башка адреска җибәрү турында хәбәр булырга тиеш. Мөрәҗәгать итүче мондый шикаятькә кирәкле документларны һәм материалларны электрон формада теркәргә хокуклы.

7.4. Судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү предметы булып мөрәҗәгать итүче фикеренчә, аның хокуклары, ирекләре яки законлы мәнфәгатьләре бозылуга китергән ТР ДТИ вазыйфаи затларының дәүләт функциясен башкарганда кылган яисә кабул иткән гамәлләре (гамәл кылмаулары) яисә карарлары тора.

7.5. ТР ДТИ яисә, компетенцияләре нигезендә, югары торучы вазыйфаи затка килгән шикаять зарури тәртиптә каралырга тиеш. Шикаятьне карап тикшерүдән баш тарту яисә карауны туктату өчен нигезләр каралмаган.

7.6. Әгәр язмача шикаятьтә шикаятьне җибәргән гражданинның фамилиясе яисә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы күрсәтелмәгән булса, шикаятькә җавап бирелми. Әгәр бу шикаятьтә хокукка каршы килә торган гамәлнең әзерләнүе, кылынуы яки кылынганлыгы турында, шулай ук аны әзерләүче, кылучы яки кылган зат турында белешмәләр булса, шикаять компетенциясенә ярашлы рәвештә дәүләт органына җибәрелергә тиеш.

Суд карарына шикаять белдерелә торган шикаять, теркәлгән көннән башлап җиде көн дәвамында, шикаятьне юллаган мөрәҗәгать итүчегә әлеге суд карарына шикаять белдерү тәртибен аңлатып, кире җибәрелә.

Цензурасыз яисә мыскыллы җөмләләрне, вазыйфаи затның, шулай ук

аның гаилә әгъзаларының гомеренә, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә янауларны үз эченә алган язмача мөрәҗәгать килгән очракта, мөрәҗәгатьне анда күтәрелгән мәсьәләләрнең асылы буенча җавапсыз калдырырга һәм мөрәҗәгатьне җибәрүче гражданинга хокук белән исәпләшмәүнең ярамаганлыгы турында хәбәр итәргә хокуклы.

Цензурасыз яисә мыскыллы җөмләләрне, вазыйфаи затның, шулай ук аның гаилә әгъзаларының гомеренә, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә янауларны үз эченә алган язмача мөрәҗәгать килгән очракта, ТР ДТИ мөрәҗәгатьне анда күтәрелгән мәсьәләләрнең асылы буенча җавапсыз калдырырга һәм мөрәҗәгатьне җибәрүче гражданинга хокук белән исәпләшмәүнең ярамаганлыгы турында хәбәр итәргә хокуклы.

Әгәр язмача мөрәҗәгатьнең тексты укылышлы булмаса, мөрәҗәгатькә җавап бирелми, һәм ул карау өчен дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка аларның компетенцияләренә туры китереп җибәрелергә тиеш түгел, бу хакта мөрәҗәгатьне теркәү көненнән башлап җиде көн эчендә мөрәҗәгатьне юллаган гражданинга хәбәр ителә, әгәр аның фамилиясе һәм почта адресы укылышлы булса.

Әгәр язмача мөрәҗәгать тексты җөмләнең, гаризаның яисә шикаятьнең асылын ачыкларга мөмкинлек бирмәсә, шикаятькә җавап бирелми һәм ул ул карау өчен дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка алар компетенциясенә туры китереп җибәрелергә тиеш түгел, бу хакта шикаятьне теркәүгә алган көннән соң җиде көн эчендә шикаятьне җибәргән гражданинга хәбәр ителә.

Әгәр язмача шикаятьтә аның асылы буенча, элек җибәрелгән шикаятьләргә бәйле рәвештә, инде берничә мәртәбә язмача җаваплар бирелгән сорау бәян ителгән булса һәм шул ук вакытта шикаятьтә яңа дәлилләр яисә шартлар китерелмәсә, ТР ДТИ башлыгы, ТР ДТИ башлыгы урынбасары, күрсәтелгән шикаятьнең һәм элек җибәрелгән шикаятьләрнең ТР ДТИ яисә ТР ДТИнең шул бер үк вазыйфаи затына җибәрелгән булуы шарты белән, чираттагы шикаятьнең нигезсез булуы һәм әлеге мәсьәлә буенча мөрәҗәгать итүче белән язышуны туктату турында карар кабул итәргә хокуклы. Әлеге карар турында шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә.

59-ФЗ номерлы федераль законның 10 статьясының 4 өлешенә туры китереп, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге ТР ДТИ рәсми сайтында җавабы урнаштырылган сорауны үз эченә алучы язмача шикаять килгән очракта, шикаятьне юллаган затка шикаятьне теркәүгә алган көннән соң җиде көн эчендә, шикаятьтә куелган сорауга «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә җавап урнаштырылган рәсми сайтның электрон адресы турында хәбәр ителә, бу вакытта суд карарына шикаять белдерелә торган шикаять кире кайтарылмый.

Әгәр шикаятьтә куелган мәсьәләнең асылы буенча дәүләт серен яисә федераль законда саклана торган бүтән серне тәшкил итүче белешмәләрне таратмыйча җавап биреп булмаса, шикаятьне юллаган мөрәҗәгать итүчегә күрсәтелгән белешмәләрне таратуның мөмкин булмавына бәйле рәвештә куелган мәсьәләнең асылы буенча җавап бирү мөмкинлеге булмау турында хәбәр ителә.

Әгәр шикаятьтә күтәрелгән мәсьәләләрнең асылы буенча җавап бирү мөмкинлеге булмаган сәбәпләр алга таба бетерелсә, мөрәҗәгать итүче шикаятьне ТР ДТИ кабат җибәрергә хокуклы.

7.7. Юридик затлар, шәхси эшкуарлар, физик затлар шикаятьне нигезләү һәм карап тикшерү өчен кирәкле булган мәгълүматларны һәм документларны алырга хокуклы. Мондый төр мәгълүматларны һәм документларны алу өчен юридик затлар, шәхси эшкуарлар, физик затлар ТР ДТИ адресына тиешле гарызнамәне язмача яисә электрон рәвештә җибәрергә тиеш. ТР ДТИ вазыйфаи затлары юридик затка, шәхси эшкуарга, физик затка, гарызнамәне теркәүгә алган көннән соң 30 календарь көн эчендә, аның хокукларына һәм ирекләренә турыдан-туры кагыла торган документлар һәм материаллар белән танышу мөмкинлеген бирергә тиеш, әгәр дә мәгълүматларга карата Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләмәләр булмаса.

7.8. ТР ДТИ вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) һәм карарларына карата шикаять ТР ДТИ җитәкчесенә җибәрелә. ТР ДТИ җитәкчесе гамәлләренә (гамәл кылмавына), карарларына шикаять Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрелергә мөмкин.

7.9. Шикаятьне карау чоры аны теркәгән вакыттан башлап исәпләнә. Язма шикаять ТР ДТИ кергәннән соң өч көн эчендә теркәлә.

7.10. ТР ДТИ алынган язма шикаять аны теркәгәннән соң 30 календарь көн эчендә каралырга тиеш. Аерым очракларда, шулай ук запросны башка дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына яисә вазыйфаи затка җибәргән очракта, ТР ДТИ җитәкчесе йә вәкаләтле зат шикаятьне карау срогын озайтырга хокуклы, ләкин шикаять җибәргән мөрәҗәгать итүченең шикаятен карау срогын озайту турында белдерүе белән 30 календарь көннән дә артмаска тиеш.

7.11. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча ТР ДТИ башлыгы мөрәҗәгать итүченең таләпләрен канәгатьләндерү һәм шикаять белдерелгән гамәлләр (гамәл кылмау) һәм/яки карарларның хокуксыз дип тану яисә мөрәҗәгать итүченең таләпләрен канәгатьләндерүдән баш тарту турында Карар кабул итә.

7.12. Әгәр шикаятьне карау нәтиҗәсендә нигезле дип танылса, ТР ДТИ вазыйфаи затына, дәүләт хезмәткәренә, гамәл кылмау (гамәл кылмау) өчен җаваплы һәм/яки алар тарафыннан әлеге регламент нигезендә дәүләт

функцияләрен үтәү барышында кабул ителгән һәм мөрәҗәгать итүченең шикаятенә китергән хокук бозуларны бетерү (гамәл кылмау) һәм дисциплинар җаваплылык чараларын куллану буенча гамәлләр үткәрү турында карар кабул ителә.

7.13. Шикаять буенча карар барлык материаллар һәм доказательства нигезендә аларның җыелма формасында язма рәвештә чыгарыла. Ул алга таба аңа шикаять бирү тәртибенә күрсәтмә һәм тиеш.

7.14. Судка кадәр шикаять бирү нәтиҗәсе кызыксынган затка ТР ДТИ башлыгы кул куйган язма җавап рәвешендә хәбәр ителә.

7.15. Телдән шикаятьтә бәян ителгән фактлар һәм хәлләр күренеп торган һәм өстәмә тикшерү таләп итмәгән очракта, гражданин ризалыгы белән мөрәҗәгатькә шәхси кабул итү барышында телдән җавап бирелергә мөмкин, бу хакта гражданинны шәхси кабул итү карточкасында язу теркәлә. Калган очракларда шикаятьтә куелган сорауларның асылы буенча язмача рәвештә җавап бирелә.

7.16. Шикаять буенча судка кадәр шикаять бирү нәтиҗәсе, электрон документ формасындагы затка шикаятьтә күрсәтелгән электрон почта адресы буенча яки шикаятьтә күрсәтелгән почта адресы буенча язмача җибәрелә.

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензия контролендә тоту буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына 1 нче кушымта

(Типлаштырылган форма Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган)

__________________________ «__» _____________ 20__ ел.
(актны төзү урыны) (актны төзү датасы)

__________________________
(акт төзү вакыты)

Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы, муниципаль контроль органы тарафыннан юридик затны, шәхси эшкуарны тикшерү акты № _______

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензия контролендә тоту буенча дәүләт

функциясен үтәүнең административ
регламентына 2 нче кушымта

| | |
|---|---|
| ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ДӘҮЛӘТ ТОРАК<br>ИНСПЕКЦИЯСЕ | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫНЫН<br>ДЭУЛЭТ ТОРАК<br>ИНСПЕКЦИЯСЕ |

(торак зонасы инспекциясенең исеме) (торак зонасы инспекциясенең исеме)

тел/факс 236-91-44. E-mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru

Район _________________ Торак пункт ___________________

Лицензия таләпләрен бозуларны бетерү турында N ____ күрсәтмә

«__» _________ 20__ ел.

Бирелде
______________________________________________________________________
(лицензиатның исеме)
Лицензиатның объекты: урам ___________ йорт N ____ корп. N ____ ф. N ___
Объектның характеристикасы: материал: стеналар ___________, түбә _______________;
катлар ___, саны: секцияләр ___, фатир ___; гом. мәйданы (кв. м) ____,
файдалануга тапшыру елы_________.
Тикшерү үткәрелде: _____________________________________________
(объект буенча тулаем алганда, секция, фатир, подвал, түбә, йорт яны терр. һәм башкалар буенча)
______________________________________буенча тикшерелгән мәйдан _____ кв. м.
(сәбәбен күрсәтергә: график буенча, шикаять нигезендә h.б.)

Ачыкланган житешсезлекләр: Россия Федерациясе Торак кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 21 гыйнварындагы 25 номерлы карары белән расланган Торак биналардан файдалану кагыйдәләре, Россия Дәүләт төзелеш күзәтчелегенең 2003 елның 27 сентябрендәге 170 номерлы карары белән расланган Торак фондын техник эксплуатацияләү кагыйдәләре һәм нормалары, Төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре, Ведомство төзелеш нормалары, РФ Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортларда һәм торак йортларда милекчеләргә һәм торак урыннардан файдаланучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтү турында» 2011 елның 6 маендагы 354 номерлы карары («Күпфатирлы йортларда һәм торак йортларда милекчеләргә һәм торак урыннардан файдаланучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтү кагыйдәләре» белән берлектә), РФ Хөкүмәтенең 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы карары белән расланган Күпфатирлы йортларда уртак мөлкәтне карап тоту кагыйдәләре h.б.

| т/с | Норматив документның пункт номеры | Бозуга сыйфатлама | Эшләрнең исемлеге һәм атамасы | Бетерү вакыты |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |

____ б. нигезләмәне кар.

Әлеге күрсәтмәне үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта юридик зат, вазыйфаи зат Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 19.5 ст. 24 өлеше нигезендә административ җаваплы була.

Дәүләт торак инспекторы ______________________ ________________________________________
(имза) (Ф.И.А.)

Күрсәтмәне алды ____________________________ ______________________________-
(имза) (фамилия, исем, ата исеме, вазыйфа)

Тикшерүдә катнашучылар:

______________________________________ ______________

(Ф.И.А., вазыйфа, оешма) (имза)

______________________________________ ______________

(Ф.И.А., вазыйфа, оешма) (имза)

Махсус тамгалар:

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

20___ елның «___» _____________ № ___ күрсәтмәгә кушымта

| т/с | Норматив документның пункт номеры | Бозуга сыйфатлама | Эшләрнең исемлеге һәм атамасы | Бетерү вакыты |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |

Дәүләт торак инспекторы _____________________ __________________________________
(имза) (фамилия, исем, ата исеме)
Күрсәтмәне алды __________________________ ____________________________-
(имза) (фамилия, исем, ата исеме, вазыйфа)

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензия контролендә тоту буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына 3 нче кушымта

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫН ДЭУЛЭТ ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ

(торак зонасы инспекциясенең исеме) (торак зонасы инспекциясенең исеме)

тел/факс. 236-91-44. E-mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru

---

Район __________________ Торак пункт ____________________

Административ хокук бозу турында №________ БЕРКЕТМӘ

«__» __________ 20__ ел.
___ сәг. ____ мин.

Дәүләт торак инспекторы _____________________ __________________________________
бу беркетмәне төзеде, түбәндәгеләр хакында:
Атамасы____________________________________________________________________
(юридик затныкы яисә физик затның, шәхси эшкуарның Ф.И.А,, адресы)
Законлы вәкил: юридик затныкы, вазыйфаи яки физик затныкы, шәхси эшкуарныкы
_______________________________________________________________________
(Ф.И.А., вазыйфасы, эш урыны)
_____________________ Ышанычнамә N _____ ____________________________
Элегрәк Административ хокук бозулар турында РФ кодексының
___ ст. ____ өлеше буенча __________________________________
(җәлеп ителде, җәлеп ителмәде)

Вазыйфаи (физик) зат ____________________________________________________________
(Фамилия, исем, ата исеме)
Туу көне, ае, елы ________________________ Туу урыны _________________________
____________________________________________ Гражданлыгы ___________________________
Эш урыны ____________________________________________________________________
(предприятие, оешма исеме, вазыйфа, юридик адрес)
Яшәү урыны буенча адресы ________________________________________________________
_________________________________________________________________________________
Элегрәк Административ хокук бозулар турында РФ кодексының
___ ст. ____ өлеше буенча ____________________________________
(җәлеп ителде, җәлеп ителмәде)
Административ хокук бозу объекты: урам ___________________________________
йорт № _____ корп. N ____ ф. N ___.
Административ хокук бозуны кылу датасы, вакыты һәм урыны: «___»
______________ 20__ ел. «__» сәг «__» мин.
Административ хокук бозу составы: ________________________________________
_________________________________________________________________________________

| т/с | Норматив актның статьясы, пункты (ЖК, ППЖП, ПиН, СНиП, ВСН и др.) <*> | Бозуга сыйфатлама |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | |
| | | |

--------------------------------

<*> Россия Федерациясе Торак кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 21 гыйнварындагы 25 номерлы карары белән расланган Торак биналардан файдалану кагыйдәләре, Россия Дәүләт төзелеш күзәтчелегенең 2003 елның 27 сентябрендәге 170 номерлы карары белән расланган Торак фондын техник эксплуатацияләү кагыйдәләре һәм нормалары, Төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре, Ведомство төзелеш нормалары, РФ Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортларда һәм торак йортларда милекчеләргә һәм торак урыннардан файдаланучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтү турында» 2011 елның 6 маендагы 354 номерлы карары («Күпфатирлы йортларда һәм торак йортларда милекчеләргә һәм торак урыннардан файдаланучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтү кагыйдәләре» белән берлектә), РФ Хөкүмәтенең 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы карары белән расланган Күпфатирлы йортларда уртак мөлкәтне карап тоту кагыйдәләре һ.б.

____ б. нигезләмәне кар.

моның өчен Административ хокук бозулар турында РФ кодексының ______ ст. ______ өл. җаваплылык каралган. Җаваплылыкка тартылучы затның РФ Конституциясенең 51 ст. 1 өлешендә, Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 25.1 ст. каралган хокуклары һәм бурычлары аңлатылды___________________________________
(имза, Ф.И.А.)
Үзенә карата административ хокук бозу турында эш кузгатылган затның (аның вәкиленең) аңлатмасы
_________________________________________________________________________________

_______________________________________________________________________
(имза, Ф.И.А.)
Дәүләт торак инспекторы ___________________ ______________________________
мөһер урыны (имза) (Ф.И.А.)
Шаһит

_______________________________________________________________________
(Ф.И.А., имза, адрес)
_______________________________________________________________________
(Ф.И.А., имза, адрес)
Зыян күрүче __________________________________________________________
(Ф.И.А., имза, адрес)
_______________________________________________________________________
(Ф.И.А., имза, адрес)
Беркетмәгә теркәлә: __________________________________________________
_______________________________________________________________________
Административ хокук бозу турындагы эшне карау урыны һәм вакыты ___ сәгать ___ минут, 20___ елның «__» ________, адрес: _______________________
(эш ТР ДТИ органнары тарафыннан каралганда)
Эш җәмәгать судында каралачак ___________________________________________
_______________________________________________________________________
(эш җәмәгать судында каралганда)
Беркетмә белән таныштым
беркетмә күчермәсен алдым__________________ «__» ________ 20__ ел.
(беркетмәне алган затның имзасы, Ф.И.А.)

РФ Конституциясе (51 ст. 1 өл.). Беркем дә үз-үзенә, тормыш иптәшенә һәм даирәсе Федераль законда билгеләнә торган якын туганнарына каршы шаһитлык итәргә тиеш түгел.

Административ хокук бозулар турында РФ кодексы (алга таба – Кодекс) (25.1 ст.). Үзенә карата административ хокук бозу турында эш буенча эш алып барыла торган зат эшнең барлык материаллары белән танышырга, аңлатмалар бирергә, дәлилләр китерергә, үтенечләр һәм каршы чыгулар белдерергә, яклаучының юридик ярдәменнән файдаланырга хокуклы, шулай ук әлеге Кодекс нигезендә бүтән процессуаль хокуклардан файдалана ала. Административ хокук бозу турында эш үзенә карата административ хокук бозу турында эш буенча эш алып барыла торган зат катнашында карала. Күрсәтелгән зат юклыгында эш бары тик Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 28.6 ст. 3 өлешендә каралган очракларда йә эшне карау урыны һәм вакыты турында затка тиешенчә хәбәр итү турында белешмәләр булганда һәм заттан эшне карап тикшерүне кичектерү турында үтенеч алынмаганда яисә мондый үтенеч канәгатьләндерелмичә калган очракларда гына карала ала.

20___ елның
«___»___________
№____ беркетмәгә
кушымта

Административ хокук бозу составы: Россия Федерациясе Торак кодексы, Россия

Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 21 гыйнварындагы 25 номерлы карары белән расланган Торак биналардан файдалану кагыйдәләре, Россия Дәүләт төзелеш күзәтчелегенең 2003 елның 27 сентябрендәге 170 номерлы карары белән расланган Торак фондын техник эксплуатацияләү кагыйдәләре һәм нормалары, Төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре, Ведомство төзелеш нормалары, РФ Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортларда һәм торак йортларда милекчеләргә һәм торак урыннардан файдаланучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтү турында» 2011 елның 6 маендагы 354 номерлы карары («Күпфатирлы йортларда һәм торак йортларда милекчеләргә һәм торак урыннардан файдаланучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтү кагыйдәләре» белән берлектә), РФ Хөкүмәтенең 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы карары белән расланган Күпфатирлы йортларда уртак мөлкәтне карап тоту кагыйдәләре һ.б.

| т/с | Норматив документ пункты номеры | Бозуга сыйфатлама |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |

Дәүләт торак инспекторы ________________ __________________________
(имза) (Ф.И.А.)
Шаһит
_____________________________________________________________________
(Ф.И.А., имза, адрес)
_____________________________________________________________________
(Ф.И.А., имза, адрес)
Зыян күрүче ___________________________________________________________
(Ф.И.А., имза, адрес)
_____________________________________________________________________
(Ф.И.А., имза, адрес)
Беркетмә белән таныштым, беркетмә күчермәсен алдым_______________________________

(беркетмәне алган затның имзасы, Ф.И.А.)

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензия контролендә тоту буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына 4 нче кушымта

## ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕН ҮТӘҮ БУЕНЧА БЛОК-СХЕМА

Лицензия таләпләре бозылуны профилактикалауга юнәлдерелгән чараларны оештыру һәм уздыру

Ел саен үткәрелә торган планлы тикшерүләрне уздыру планын төзү һәм

Планнан тыш тикшерүләрне уздыру өчен нигезләр барлыкка килү

ТР ДТИ башлыгы (башлыгы урынбасары) тарафыннан планлы яисә планнан тыш (документ һәм (яки) урынга чыгып) тикшерү уздыру турында күрсәтмә әзерләү һәм имзалау, билгеләнгән очракларда планнан тыш урынга чыгып тикшерүне прокуратура органнары белән килештерү

Хәбәр итмичә тикшерү уздыру

Юридик затка яисә шәхси эшкуарга тикшерү уздырылачагы турында хәбәр итү

Лицензиатларга, лицензия алырга теләүчеләргә карата тикшерү уздыру һәм тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү

Тикшерү актын төзү, лицензиатка, лицензиягә дәгъва кылучыга кул куйдыртып тапшыру (электрон документ формасында җибәрү, уздырылган кучмә тикшерү турындагы язуны тикшерүләрне исәпкә алу журналында теркәү (булган очракта)

Җитешсезлекләр ачыкланмаса, дәүләт функциясен үтәүне төгәлләү

Ачыкланган бозуларны бетерү буенча чаралар күрү




Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензия контролендә тоту буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына 5 нче кушымта

**ТИКШЕРҮЛӘР УЗДЫРГАНДА ТР ДТИ ВЕДОМСТВОАРА МӘГЪЛҮМАТИ ХЕЗМӘТТӘШЛЕК ИТҮЕ КЫСАЛАРЫНДА ДОКУМЕНТЛАР ҺӘМ (ЯИСӘ) МӘГЪЛҮМАТЛАР БЕЛӘН ЭШ ИТҮЧЕ БАШКА ДӘҮЛӘТ ОРГАННАРЫННАН, ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ ОРГАННАРЫННАН ЯИСӘ ОЕШМАЛАРДАН СОРАТЫЛА ТОРГАН ӘЛЕГЕ ДОКУМЕНТЛАРНЫҢ ҺӘМ (ЯИСӘ) МӘГЪЛҮМАТЛАРНЫҢ ИСЕМЛЕГЕ**

| Соратыла торган документның аталышы һәм (яисә) соратыла торган мәгълүмат | Документлар һәм (яисә) соратыла торган мәгълүматлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы, оешма |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Дәүләт пошлинасын түләү турында белешмәләр | Федераль казначылык |
| Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр | Россиянең Федераль салым хезмәте |
| Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр | Россиянең Федераль салым хезмәте |
| Алдагы календарь елында хезмәткәрләрнең | Россиянең Федераль салым хезмәте |

| | |
|---|---|
| уртача исемлек саны турында белешмәләр | |
| Кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрыннан белешмәләр | Россиянең Федераль салым хезмәте |
| Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан күчемсез мөлкәт объекты турында өземтә | Росреестр |
| Территориянең кадастр планы | Росреестр |
| Квалификациясе алынган затлар реестрыннан белешмәләр | Россиянең Федераль салым хезмәте |
| лицензия алырга теләүченең вазыйфаи затында икътисад өлкәсендәге җинаятьләр, уртача авырлыктагы җинаятьләр, авыр һәм аеруча авыр җинаятьләр өчен алынмаган яки үтәлмәгән суд хөкеме булуы (булмавы) турында белешмәләр | Россия Эчке эшләр министрлыгы |
| Лицензия алырга теләүченең вазыйфаи заты турында лицензиясе гамәлдән чыгарылган лицензиатның бер кулдагы башкарма органы функцияләрен башкаручы затлар, шулай ук лицензиатның уставында яки бүтән документларында күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне тиешенчә карап тотуны тәэмин итүгә карата таләпләр үтәлеше өчен җаваплылык йөкләнгән һәм үзләренә карата квалификациясеннән мәхрүм ителү кебек административ җәза кулланылган затлар, лицензиясе гамәлдән чыгарылган һәм (яки) үзләренә карата квалификациясеннән мәхрүм итү кебек административ җәза кулланылган шәхси эшкуарлар реестрында мәгълүмат булуы (булмавы) турында, шулай ук лицензияләрнең җыелма федераль реестрында лицензия алырга теләүчегә элегрәк бирелгән лицензияне гамәлдән чыгару турында мәгълүматларның булмавы турында белешмәләр | Россиянең Төзелеш министрлыгы |
| Җирле үзидарә органыннан күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен, түләү билгеләү турында белешмәләр | Җирле үзидарә органы |
| Бинаны торак урын, торак урынны яшәргә яраксыз һәм күпфатирлы йортны аварияле һәм сүтелергә яисә үзгәртеп корылырга тиешле дип тану мәсьәләсе буенча гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау нәтиҗәләре буенча эшләрнең материаллары | Җирле үзидарә органы |
| Аварияле һәм сүтелергә тиешле дип танылган күпфатирлы йортлар исемлеге | Җирле үзидарә органы |

| | |
|---|---|
| Торак урынны торак булмаган урынга һәм торак булмаган урынны торак урынга күчерү материаллары | Җирле үзидарә органы |

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензия контролендә тоту буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына 6 нчы кушымта

(Типлаштырылган форма Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган)

Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы
КҮРСӘТМӘСЕ (БОЕРЫГЫ)

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензия контролендә тоту буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына 7 нче кушымта

(Типлаштырылган форма Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган)

Юридик затка, шәхси эшкуага планнан тыш урынга чыгып тикшерү уздыруны дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы тарафыннан прокуратура белән килештерү турында гариза

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензия контролендә тоту буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ

регламентына 8 нче кушымта

| ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫН ДЭУЛЭТ ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ |
|---|---|---|

(торак зонасы инспекциясенең исеме) (торак зонасы инспекциясенең исеме)

тел/факс. 236-91-44. E-mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru

______________________________________________________________________

Күрсәтмәне үтәү вакытын арттыру озынайту турында белдерү

«___»________ 20__ ел N ________________

АДРЕС: ________________________________________________________________
КЕМГӘ: ________________________________________________________________
(оешма җитәкчесенең вазыйфасы, Ф.И.А.; физик затның (гражданинның, ШЭ, вазыйфаи затның вазыйфасын күрсәтеп) Ф.И.А.)

______________________________________________________________________

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе Сезгә 20___ елның «___» __________ керү № ____ мөрәҗәгатегезне карау нәтиҗәләре буенча 20 __ «___»_________ № _____ күрсәтмәне үтәү срогын озынайту турында карар кабул ителүе хакында хәбәр итә, шуңа бәйле рәвештә Сезгә яки Сезнең тиешенчә рәсмиләштерелгән ышанычнамәсе булган вәкилегезгә 20 ___ елның «___» ________________ ___ сәгатьтә түбәндәге адрес буенча килергә кирәк:

______________________________________________________________________

срокны озынайту турында язу кертү өчен күрсәтмәнең төп нөсхәсе белән.

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе башлыгы (җитәкче урынбасары ) ______________________ ________________

(имза) (фамилия, исем, ата исеме)

Хәбәрнең күчермәсе җибәрелде (тапшырылды): _______________________

______________________________________________________________________